Шәһри Казан

СИШӘМБЕ, 15 ГЫЙНВАР, 2013 ЕЛ,
N 5 (5183)
WWW.SHAHRIKAZAN.COM

1990 елдан бирле чыга

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

7 бит

«КУАНЫЧЫМНАН ЕЛЫЙМ»

8 бит

САЛЫМНАР АРТА

11 бит

АЛТЫДАГЫ — АЛТМЫШКА

КӨН АВАЗЫ

Россия министрлыклары исемлеге тагын бер ведомствога артырга мөмкин. РФ Премьер-министры Дмитрий Медведев Табигый ресурслар министрлыгын кабат булдыру мәсьәләсен эшләргә кушкан. Әлеге министрлык балыкчылык тармагы, урман һәм аучылык хуҗалыгын көйләү белән шөгыльләнәчәк. Яңа министрлык өчен нигез булып Россия балыкчылык институты торачак. Мондый карарның сәбәбен, әлеге ведомство Авыл хуҗалыгы министрлыгына буйсына башлагач, балык тоту һәм аны җитештерү күрсәткечләренең кимүендә күрәләр.

* * *

Россия юлларында радар турында кисәтүче билгеләр барлыкка киләчәк. Эчке эшләр министрлыгы хөкүмәткә машина йөртүчеләрне видеокүзәтү һәм радарлар урнаштырылган урынга якынлашу хакында кисәтә торган билгеләрне кертү турындагы проектны тәкъдим иткән, дип яза «Известия» газетасы.

* * *

Армиядә аяк чолгавы башка кулланылмаячак. Оборона министры Сергей Шойгу белдергәнчә, бу елның ахырына кадәр аяк чолгавы хәрби хезмәткәрләрнең форма элементы булудан туктаячак. Аныңча, хәрби хезмәттә моннан тулысынча баш тартырга кирәк.

* * *

Илле яшьтән олырак хатын-кызларга диета ярдәмендә ябыгу сәламәтлек өчен куркыныч. Америка галимнәре тикшерүенчә, диетаның үзе түгел, ә элеккеге туклану рационына кайту сәламәтлек өчен зур сынау булып тора. Эш шунда – бу очракта йөрәк-кан тамырлары һәм шикәр чире барлыкка килү куркынычы арта ди.

2 бит

Дамир БӘДРИЕВ фотосы

ТАТАР БИСТӘЛӘРЕНӘ ҖАН КЕРӘ

ЗАКОН ЯҢАРДЫ, ТӘРТИП ҮЗГӘРЕРМЕ?

5 бит

«ШК» газетасының 17 гыйнвар — пәнҗешәмбе санына алхәбәр

«Иманыбызның ныклыгы шуның кадәр генәдер инде. Без, үзебез дә сизмәстән, яңадан-яңа юк-бар ырымнар уйлап чыгара башладык. Беркөнне әни бик матур үрмә гөл алып кайтты. Күрше апа: «Ирләрне өйдән биздерә бу гөл», — дип чыгарып атарга җыенган икән аны».
Мәрьям АБДУЛЛИНА. «Һәр өйдә — күрәзәче...»

7 бит

«Бездә бит клип төшерә белмиләр, дип сүгеп тә булмый. Җырчылар һәрвакыт эзләнүдә. Аның өчен өйрәнү мәктәбе юк. Әлеге мәктәпне булдырырга кирәк. Аннан инде гел яхшы клиплар белән генә мактанып утырып булачак».
Гөлнара ҖӘЛИЛОВА. «Арыш басуы, Мерседес, әткәй белән әнкәй...»

9 бит

«Балаларың бозыкка баскан. Үлемнән сезне олы хайван саклап калган. Син аларны дәвалый алмыйсың. Тәмле ашат, матур киендер, кулларына буяу бир», — дип озатып кала аны багучы».
Люция ХӘБИБУЛЛИНА. «Балаларың бозыкка баскан»

11 бит

ОЧТЫ-КИТТЕ

ӘЙТКӘН СҮЗ — АТКАН УК

Илсур МЕТШИН,
Казан мэры:

— Казанның борынгы өлешен «клиник үлем»нән коткарып, «тернәкләндерү» палатасына чыгардык. Аллаһы боерса, тиздән йөреп тә китәр.

(«Эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә Иске Татар бистәсен төзекләндерүгә мөнәсәбәтле әйткән сүзләре)

«Шәһри Казан»да бергә кайныйк! Телефоннарыбыз: (843) 562-50-07 (факс), 562-50-12

РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР

Ут бетеп торачак

КАЗАННЫҢ Идел буе районындагы кайбер йортларда 14-20 гыйнвар көннәрендә ут бетеп тору ихтималы бар.

Бу электр чыбыкларын, трансформатор станцияләренең электротехника җиһазларын планлы төстә төзәтү белән бәйле. 14еннән 20сенә кадәр иртәнге 9.00дән 17.00 сәгатьләргә кадәр Калиновка бистәсендә – Школьная, Сармовская, Түмән, Аркылы Сармовская урамнарында, Победилово бистәсендә – 1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче, 5 нче Победилово урамнарында, Мирный бистәсендә – 8 нче, 6 нчы, 3 нче Дәүләки, 1 нче һәм 2 нче Новосельская урамнарындагы йортларда ут бетеп торачак.

Белемеңне сынап кара

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы БДИ буенча белемнәрне тикшерә башлады.

Министрлык, Бердәм дәүләт имтиханын уңышлы тапшыруга әзерләү максатыннан, Казан федераль университеты белән берлектә, 2013 елның 15-18 гыйнвар көннәрендә 11 нче сыйныф укучылары өчен тестлаштыру оештыра. Рус теленнән һәм математикадан On-line режимында белемнәреңне сынап карарга була. Моның өчен www.abiturient.kpfu.ru адресы буенча теркәлергә кирәк, дип хәбәр итә министрлыкның матбугат хезмәте.

Әйләнечтән юл яхшырак

БИЕКТАУ станциясендәге тимер юл төзекләндерү эшләре автомобильләр хәрәкәтенә үзгәрешләр кертә.

21 гыйнвар иртәнге сәгать 8дән 31 гыйнвар кичке сәгать 6га кадәр Биектау станциясендә тимер юл полотносы төзекләндереләчәк. Әлеге эшләр вакытында 812 нче километрдагы магистраль аша чыгу урыны автомобиль хәрәкәте өчен ябыла. Автомобиль йөртүчеләргә бу вакыт аралыгында 815 нче километрдагы юл полотносы аша узарга киңәш ителә.

Волонтер булырга теләсәң...

БҮГЕН Казан илкүләм тикшеренү-технологик университетында Универсиада-2013 волонтерларын җыю (рекрутинг) үзәге ачылачак.

Искәртеп узабыз, 2013 елгы җәйге Универсиада барышында 20 мең волонтер эшкә җигеләчәк. Агымдагы елның мартына кадәр дәвам итәчәк анкеталарны тикшерү һәм үткәрелгән әңгәмәләргә йомгак ясау процессын барлыгы 50 мең 319 кандидат көтә. Алар арасында Россия шәһәрләреннән һәм башка илләрдән дә кандидатлар бар. Февраль аенда беренче кандидатларга Универсиаданы оештыручылардан волонтерлык позициясе, объект исеме һәм функциональ вазифалар күрсәтелгән хатлар барып ирешәчәк.

СОРАШТЫРУ

Сүзлекләр ышанычлырак

Бүген бөтендөнья интернет челтәрендә ирекле тарала торган универсаль энциклопедия – Википедиянең туган көне. Интернет кулланучылары арасында популяр булган әлеге энциклопедия дөньяның иң күп кулланыла торган ун интернет-ресурсы арасына кергән. Ә сез Википедиягә еш мөрәҗәгать итәсезме?

Нияз хәзрәт Сабиров, Казан ислам көллияте директорының урынбасары:

– Бик еш булмаса да, мөрәҗәгать иткәлим. Үземне кызыксындырган сорауга җавапны мин китаплардан табарга яратам. Әммә мәгълүмат бик тиз кирәк булганда, Википедиядән карыйм. Андый очракларда аны бик җайлы күрәм.

Илдар Абитов, психолог:

– Юк, бик сирәк. Бары ике-өч тапкыр гына мөрәҗәгать иткәнмендер. Мин сүзлекләрдән карауны кулайрак табам һәм аларга ышанам. Ни өчен дигәндә, аларның конкрет авторлары бар. Шуңа да Википедиягә бик сак карыйм.

Айгөл Сафина, газета укучы:

– Википедия ул бик җайлы нәрсә. Аның татарчасы да бар дип ишеткәч, интернеттан эзләп караган идем. Бар барын, әмма анда мәгълүмат бик сай.

КАЗАН ХӘБӘРЛӘРЕ

Иске һәм Яңа Татар бистәләренә җан керә

«Иске шәһәр» префектурасындагы 12 урамда 55 бинаны торгызу эшләре бара.

УНИВЕРСИАДА СУЛЫШЫ

Дамир БӘДРИЕВ

Автор фотосы

«Иске шәһәр» («Старый город») префектурасы, Казан шәһәр Думасы карары нигезендә, 2011 елның 22 сентябрендә оештырылган иде. Префектура биләмәләренә Иске Татар һәм Яңа Татар бистәләренең күпчелек өлеше, Сул як Болак, Тукай һәм Мәскәү урамнары буенча урнашкан борынгы биналар, «Казан» тимер юл вокзалы, үзәк автовокзал һәм елга порты тирәләре керә. Анда федераль һәм республика әһәмиятендәге 89 тарихи-мәдәни мирас һәйкәле урнашкан.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның тарихи-мәдәни мирас һәйкәлләрен торгызу турындагы күрсәтмәсе, Универсиадага әзерлек чаралары мәсьәләнең чишелешенә уңай йогынты ясады. «Префектура җирлегендәге 14 бинаны торгызу һәм төзекләндерү тәмамланды инде», – диде «Иске шәһәр» префекты Линар Закиров. «Милләт» нәшрияты бинасы (Нариманов ур., 62), Рахманкулов йорты (Нариманов ур., 70), Усманова-Апанаева йорты (К.Насыйри ур., 40), Мәрҗәни мәчете архитектура ансамбленә караучы ике йорт (Ш.Мәрҗани ур., 16 һәм 18) – әлеге исемлектән. Тарихи документларга нигезләнелеп кабаттан торгызылган 6 агач йортның бишесе – республиканың Урман хуҗалыгы министрлыгы хезмәте. «Төзекләндерелүче 55 бинаның 42се исә тарихи архитектура һәйкәле. 13 бинаны «ASG» компаниясе төзекләндерә», – диде Линар Закиров.

Мэр Илсур Метшин, сөйләшүгә йомгак ясап: «Иске шәһәр» префектурасы Европа шәһәрләрендәге, шулай ук Баку шәһәрендәге тәҗрибәгә таянып оештырылды. Хәер, бездә «Казан посады» эшчәнлек алып барган иде инде. Казанга кунаклар һәм туристларның килүе елдан-ел арта бара. Иске Татар бистәсе кабаттан торгызылган тарихи бизәкләре белән туристларны һичшиксез үзенә җәлеп итәр», – диде.

Иске Татар бистәсендә турист маршрутлары, автобуслар һәм автомобильләр күеп тору урыннары булдырылачак. Бистәдә узган ел шәхси милектәге 23 йортның да диварлары төзекләндерелгән.

Казанның бурычы 5 миллиард кына...

Татарстан башкаласында узган ел 89 миллиард сум күләмендә салым җыелган. Бу – аннан алдагы елгыдан 69 миллиард сумга күбрәк.

ФИНАНСЛАР

Ләкин салым түләүләре дә федераль бюджетка – 29,6 миллиард, республикага – 47,4 миллиард сумга һәм муниципаль бюджетка 8,9 миллиард сумга арттырылган. Шәһәр башкарма комитетының финанс идарәсе җитәкчесе Айрат Гарипов әйткәнчә, гамәлдәге законнар нигезендә, салым түләүләрендәге һәр 1 сум акчаның 34 тиене федераль бюджетка, 55 тиене исә республика бюджетына күчерелә. Нәтиҗәдә, Казанга 11 тиен генә кала.

Узган ел башкала бюджетының керемнәре һәм чыгымнары 24 миллиард сум чикләрендә булган. Салым түләүләреннән тыш, шәһәр муниципаль милекне файдаланудан һәм сатудан, тышкы реклама корылмалары аукционнарыннан 3,5 миллиард сум керем алынган. Моның өстенә югары бюджетлардан 11,7 миллиард сум максатчан трансферт кергән, ягъни акча күчерелгән. Муниципаль бюджетның 40 процентка якыны мәгариф тармагына, 24 проценты капиталь төзекләндерүгә һәм юллар төзелешенә, 10 проценты тышкы төзекләндерүгә, 7 проценты торак фондны капиталь ремонтлауга юнәлтелгән.

Бюджет кредитларын исәпкә алмаганда, бүген Казан 4,9 миллиард сум бурычлы. Бу сан 2005 елдан – Казанның меңьеллыгы бәйрәме чорларыннан бирле ияреп килә. Шөкер, шәһәр тәэминатчыларга һәм подрядчы оешмаларга бурычын ике мәртәбәгә киметүгә ирешкән, хәзер ул 385 миллион сумны тәшкил итә.

Казан бюджетына узган ел 1 миллиард сумга якын салым түләнелми калган. Мэр Илсур Метшин: «Әлеге акчаларны суд аша барыбер түләттерәчәкбез. Бюджет акчаларын сакчыл тоту һәм муниципаль бурычны киметү өчен тырышу шәһәр хуҗалыгында үзенә күрә бер канун роленда булырга тиеш», – диде.

Сыра сатып баючыга көн юк!

Яңа ел үзе белән яңа кануннар да алып килде. Хәзер кичке сәгать 11дән иртәнге сәгать 8гә тикле сыра сату тыела. Ә мәйданы 50 квадрат метрдан ким булган биналарда аны сату бөтенләй ярамый. Канунны үтәмәүче оешмаларга – 30-40 мең, ә шәхси эшмәкәрләр һәм кибетчеләргә 3-4 мең сумлык штраф яный.

ВАЗГЫЯТЬ

Казанда күп кенә урам киоскларының суыткычлары бушап калды, икенче берләренең, тулы булуына карамастан, ишегенә «Сыра сатылмый!» ише язулар ябыштырып куелды. Әмма чынлыкта сыра сату канун буенча тыелса да, гамәлдән әле чыкмады. Киосклар өчен төп керем чыганагы булган продукты кибетчеләр яшертен рәвештә сата.

Нәтиҗәдә, яңа канунны тормышка ашыру эшенә җиң сызганып полиция кереште. Узган атнада Казан полициясенең алты йөзләп сәүдә ноктасын тикшерүе шул хакта сөйли. Канун бозу фактларын ачыклап, инде 219дан артык беркетмә төзелгән дә. Казан эчке эшләр идарәсе җитәкчесе Валерий Кравченко башкала мэриясенең «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә шул хакта җиткерде. Кравченко сүзләренә караганда, узган атнада беркетмәләр күбесе бер үк мини-маркет һәм киоск кибетчеләренә берничә мәртәбә дә тутырылган. Рейдлар барышында 2,5 литр алкоголь продукциясе конфискацияләнгән. Һәр полиция бүлегендә махсус эшче төркемнәр төзелгән. «Әгәр төнлә кайда да булса сыра сатылу ачыкланса, төркем чакырылып, беркетмәләр төзеләчәк», – ди Казан полициясе башлыгы, канунсыз сыра сатучыларны алга таба да эзәрлекләүләр дәвам итәчәген ассызыклап.

Димәк, сыра сәүдәсендә табыш алучы вак эшмәкәрләргә көн бетә, әлеге бизнес аларның кулыннан тартып алына. Бу алга таба Казан урамнарында киосклар тагы да сирәгәячәк дигән сүз. Сыра чөмереп баш тәэзетергә яратучылар өчен дә яңа мәшәкатьләр туа. Соңгылары хәзер, йоклап йөрмичә, көндез үк хәстәрен күреп куярга мәҗбүр. Тик җәмгыятьне бу юл белән айнытып булуы гына әлегә шикле. Хәер, анысын вакыт үзе күрсәтәчәк.

ҖӘМГЫЯТЬ

Динә белән Эльмирага Президент фатир тапшырды

Эльмира Кәлимуллинаның «Голос» Бөтенроссия телевизион проектының финалына чыгуы, ә Динә Гарипованың анда җиңү яулавы Татарстандагы иҗади потенциалның гаҗәеп демонстрациясе булды.

www.president.tatarstan.ru

КҮРКӘМ ГАМӘЛ

Казан Кремлендә әлеге бәйге триумфаторлары белән очрашуда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов шулай дип белдерде. Президент Динә белән Эльмираның әти-әниләренә, укытучыларына, шулай ук кызларның проекттагы остазлары Пелагия белән Александр Градский адресына рәхмәтләрен җиткерде. Аның фикеренчә, Россия шоу-бизнесына хәзер яңа талантлы башкаручылар җитми. «Голос» телевизион проекты нәкъ шундый талантларны ачты да. «Ә сез алар арасында иң яхшылары булдыгыз», – дип мөрәҗәгать итте Р.Миңнеханов Динә белән Эльмирага.

Динә Гарипова, үз чиратында, Президентка әлеге очрашу һәм җиңүдән соң юллаган котлаулар өчен рәхмәт белдерде. «Атказанган артист исемен алу – зур мәртәбә. Алга таба да без бу дәрәҗәне саклап, әлеге исемгә лаеклы булырга тырышачакбыз», – дип вәгъдә бирде җырчы. Эльмира Кәлимуллина Бөтенроссия телевизион проектындагы уңышның үзен һәм Динәне Россиянең иҗади аренасында Татарстан илчеләре итүен, моның зур мәртәбә, җаваплылык булуын ассызыклады.

Очрашуда кызлар алдагы планнары турында да сөйләде. Аларның икесе дә музыка өлкәсендә бәлем алуларын дәвам итәргә уйлый. Рөстәм Миңнеханов кызларга алга таба карьераларын дәвам итү өчен кирәкле ярдәм күрсәтеләчәген ышандырды. Очрашу соңында Президент Динә белән Эльмирага торак сертификатлары тапшырды.

* * *

Сүз уңаеннан, Яшел Үзәндә Динә Гарипова исемендәге хәйрия фондын оештырганнар. Әлеге фонд җыелган хәйрия акчасына кечкенә «йолдызчык»ларга ярдәм күрсәтәчәк.

Шәһәрнең мәдәният үзәгендә булган «Голос» проекты җиңүчесе Динә Гарипованы котлау тантанасында Яшел Үзән районы башкарма комитеты җитәкчесе Александр Тыгин шул хакта белдергән.

«Зеленодольская правда» газетасы хәбәр иткәнчә, чара барышында «Беренче канал»ның видеоязмаларын, җиңүче кызны аэропортта каршы алу кадрларын күрсәткәннәр. Динәне котларга шәһәрнең эре компанияләре җитәкчеләре дә килгән. Горький исемендәге заводның генераль директоры урынбасары Александр Карпов әйтүенчә, ул һәр программа барышында телевизор каршына ашыккан. А.Карпов Динәгә бүләк рәвешендә йөз меңлек сертификат тапшырган. Серго исемендәге завод директоры Радик Хәсәнов исә кызның әти-әнисенә – шифаханәгә путевка, ә үзенә аның портреты сурәтләнгән суыткыч бүләк иткән. Болардан кала, җиңүче кыз кер юу машинасы, ювелир эшләнмәләр һәм башка кыйммәтле бүләкләргә ия булган.

Грипның котырган чагы

БЕЛЕП ТОР!

Узган атна ахырында Казанда грипп белән авыручылар саны артык күбәеп китүе турындагы хәбәр килепирешкән иде инде. Җитмәсә, мәктәпләрдә кышкы каникуллар тәмамланып, балаларның уку йортларына кабат җыелган, бер-берләре белән ныклап аралаша башлаган вакыты да әле. Бу атна башында тагын да куркынычрак хәбәр алынды. Казанда дуңгыз гриппы белән авыручыларның саны 30га җиткән. Бу хакта Казан шәһәре сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы Рамил Әхмәтов белдерде. Әмма кешеләр күнелендә инде моннан 3-4 еллар элек үк курку тудырган дуңгыз гриппының болай артып китүеннән әллә ни куркырга кирәкми, ди ул. Дуңгыз гриппы бүгенге көндә массакүләм үпкә ялкынсынуына һәм үлем очракларына китерми.

Тик бер дә борчылмыйча да мөмкин түгел. 30 очрак – лаборатория шартларында ачыкланганнары гына, чынлыкта дуңгыз гриппы белән авыручыларның саны күбрәк дигән сүз бит инде. «Дуңгыз гриппы кечкенә балаларга һәм олы яшьтәгеләргә «ябышмый». Аның белән, нигездә, эшкә яраклы яшьтәге буын авырый. Ә аларның сәламәтлекләре нык булу сәбәпле, бу гриппны җиңел кичерәләр», – ди Казан шәһәренең сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы. Дуңгыз гриппы гадәти гриптан әллә ни аерылмый һәм вирусларга каршы препаратлар белән дәвалана, дип белдерә ул. Авыру катлауланып, үпкә ялкынсынуына китергән очраклар өчен Казан хастаханәләрендә 300 дән артык урын әзерләп куелган инде. 11 нче хастаханәдә балалар өчен тулы бер бүлек тә әзер тора. «Температуралары югары күтәрелеп, сулыш алулары авырлашкан кешеләр кичекмәстән хастаханәгә салынырга тиеш», – дип белдерә Рамил Әхмәтов.

Сүз уңаеннан: Татарстан буенча алып караганда, бүгенге көнгә дуңгыз гриппыннан үлүчеләр 2 кеше. Алар арасында балалар юк.

Бар теләкләр чынга аша

КАРАШ

Иске стиль буенча килгән Яңа елны россиялеләрнең 52 проценты билгеләп үткән, дип хәбәр итә «Левада-центр». Сораштыруны илнең 45 төбәгендәге 130 торак пунктта яши торган 18 яшьтән узган 1600 кеше арасында үткәргәннәр. Иң нык һәм бай кешеләр өчен әле тагын кытайча Яңа ел бар. Анысы 10 февральгә туры килә.

Казанның зооботаника бакчасы да иске Яңа елны билгеләп үтүчеләр рәтендә. Иске елны озату, яңасын каршылау Кыш бабай һәм Кар кызыннан башка гына булмады, билгеле. Алар да, быелга эшләрен тәмамлап, бирәсе бүләкләрен биреп бетергәннән соң, тыныч күңел белән кар патшалыкларына кайтып киттеләр. Яңа елның төп вакыйгасы – быелгы елның төп билгесе булган буар еланның теләкләре чынга ашачак кешеләрне сайлап алуы булгандыр, әлбәттә. Телəкләрен балалар 10 гыйнварга кадәр «Экзотариум»да калдырып китәргә тиешләр иде. Теләкләр язылган кәгазьләр арасыннан шуышып йөри-йөри, буар елан, теле белән күрсәтеп, 12 кешене сайлап алды. Теләкләрнең барысы да зоопарк темасы белән бәйле булырга тиешлеген әйтеп үтәргә кирәктер. Балаларның күбесе тавис кошы каурыена ия булырга теләгәннәр икән. Теләкләр арасында филне күрәсе килү, атлар җигелгән чанага утырып йөрү, ниндидер хайван белән фотога төшү кебекләре дә бар иде. Бер кыз хәтта зоопаркка ел буе бушлай керергә мөмкинлек бирүче абонементка ия булырга теләгән. Буар елан сайлап алган бәхетле балаларга бу хакта кәрәзле телефон аша хәбәр ителәчәк. «Без балалар өчен каралган чараларны атна саен үткәрергә тырышабыз. Әти-әниләр һәм балаларның ялларын әллә ни кыйммәткә төшерми генә бергәләп үткәрер урыннары булсын», – ди зооботаника бакчасының экскурсияләр бүлеге мөдире Ләйсән Алиева.

ФӘНИС МОТЫЙГУЛЛИН

Бер җенесле Евросоюз

Ни чыкмаган шул Европадан чыга инде. Алдынгы карашлы саналган бу континент кешелек дөньясын яңадан-яңа «ачышлары» белән шаккатырып тора. Шөкер, французлар кебек бака боты ашый башламадык әлегә, әмма күбебез бу «югары мәдәниятле» халыктан үрнәк алырга тырышабыз, аларча яшәргә омтылабыз. Өлге итеп алырлык нәрсәләре шактый, ләкин барысын да сукырларча алардан күчерү дә дөрес гамәл түгел.

Зәңгәрле-алсулы Франция

Узган елның маенда Франция Президенты итеп сайланганда Франсуа Олландның сайлау алды кампаниясенең төп пунктларының берсе – бер җенестәге парларның хокукларын киңәйтү иде. Соңрак Олланд берничә тапкыр бу уеннан кире кайтмаячагын белдерде, хәтта шундый беренче парның туенда катнашырга да вәгъдә бирде.

Ноябрь аенда Франция хөкүмәте бер җенестәгеләргә өйләнешергә рөхсәт итүче закон проектын хуплады. Әлеге мәсьәлә буенча парламентта гыйнвар азагында тыңлаулар узачак. Бүген бер-берсен яратышучы «төсле»ләр гражданнар союзлары гына төзи ала, ә мондый союзларның юридик яктан хокуклары аз. Закон проекты кабул ителгән очракта, Франция Европа союзында бер җенестәгеләргә гаилә кору хокукын бирүче алтынчы дәүләт булачак.

Франсуа Олландның мондый адымга баруына аптырыйсы да юк, сораштырулардан билгеле булганча, Франция халкының якынча 60 проценты бер төрле җенестәгеләрнең никахын хуплый (сайлауларда җиңеп чыгарга алар да өлешчә ярдәм иткәндер, күрәсең). Узган елның декабрендә Парижда шундыйларның никахын яклап акцияләр узды, төрле мәгълүматларга караганда, әлеге акциядә 60 меңнән 150 меңгә чаклы кеше катнашкан.

Узган якшәмбедә хөкүмәтнең мондый карарына каршы берничә йөз мең халык катнашында митинглар узды. Оештыручылары – Франциянең уң сәяси көчләре, Католик чиркәве һәм мөселманнар булган демонстрантларның төп таләбе – бер җенестәгеләргә гаилә кору хокукы бирелү уңаеннан иҗтимагый тыңлаулар уздыру. Аларның фикеренчә, хөкүмәтнең «иҗтимагый тормыш нигезләренә кагылучы» реформасы уңаеннан референдум үткәрергә кирәк.

Уйлаган кеше уйланырлык, хөкүмәтнең шундый карар кабул итүнең халыкта ыгы-зыгы уятуы тикмәгә генә түгел. Франциядә биш кешенең өчесе үз җенесендәге белән сөешеп-яратышып йөри икән, тора-бара илдә демографик кризис башланачак. Дөрес, яңа закон андыйларга уллыкка бала алуны рөхсәт итә, балалар йортлары да буш тормый торуын. Әмма бер үк җенестәге ике кешедән торган гаиләдә кайсы әни, кайсы әти икәнен белмәгән баладан нинди шәхес тәрбияләнәчәк?!

Украина кызлары — Парижда

Украинаның FEMEN хатын-кызлар хәрәкәте активистлары, бер җенестәгеләрне яклап, Парижга хәтле барып җиткән. Митингтагылар алдында ярымшәрә килеш «Без гейларга ышанабыз!» дип кычкырып торган кызлар белән католик активистлары арасында ызгыш булып алган. Узган елның сентябрендә хәрәкәт җитәкчесе И.Шевченко, Киевта тәрене кисеп аударганнан соң, Франциягә күченә, соңрак әлеге хәрәкәт бу илдә рәсми теркәлү ала. Фемениcткалар кешелеккә гей-никахлар түгел, ә дини фанатиклык куркыныч яный дип саный һәм алар Ватиканнан җенси мөнәсәбәтләргә каршы урта гасырлар уагын тергезүне туктатуны таләп итә.

«Мактаулы мордва» Жерар Депардье

Берәүләр кызык эзләп Европага тартылса, икенчеләре, киресенчә, аннан китү ягын карый. Күптән түгел генә француз актеры Жерар Депардье Россия гражданы булды. Үз илендә салым түләүдән баш тарткан әлеге танылган актер «мактаулы мордва» исемен дә алырга өлгергән. Элегрәк мондый исемгә лаек булган А.Эйнштейн, Д.Леннон, С.Джобс кебек билгеле шәхесләр белән бер рәттә булырга теләгәнме, әллә салым түләрлек мөмкинлеге юкмы яки башка сәбәпләре бармы – анысы безгә караңгы. Әмма Европада хәлләр алга таба да шулай дәвам итсә, аннан безгә таба күченүчеләр тагын булыр әле ул.

ӘЙТЕР СҮЗЕМ БАР

Бозмыйк ТУКАЙНЫ!

Тукай – халкыбызның бөек шагыйре, аның иҗаты – татарның иң кадерле хәзинәсе, дип кабатларга яратабыз. Бу хакыйкатьне инкарь итүче булмастыр да. Бәс шулай икән, ул хәзинәнең кадерен дә белергә, аның белән аеруча сак эш итәргә кирәктер бит. Ә чынлыкта без нәрсә күрәбез? Тукайның шигъри юлларыннан өзекләр китергәндә нинди генә ялгышлар җибәрелми, әле генә 125 еллыгын шаулатып үткәргән шагыйрь рухы алдында оят булып китә.

Ирек БӘДРЕТДИНОВ,
Әлмәт

Бөекләребез мирасына карата бигрәк тә сакчыл карарга тиешле әдәби басмалар – «Казан утлары» журналы белән «Мәдәни җомга» газетасе дә, әдәби мирасыбыз сагында торырга тиешле галимнәребез үзләре үк Тукай сүзләрен, мәгънәләрен бозганын күргән чакта аптырарга гына кала.

Моннан бер елдан артыграк элек, 2011 елның 15 октябрь санында «Татарстан яшьләре»ндә:

«Рус белән гомер
кичердек сайрашып,
тел-лөгать, гадәт вә
***халык** алмашып,*
Һич бетәрме бу тарихи бергәлек, без туган бер җепкә бергә теркәлеп», – дигән юлларны укырга туры килгәч, көлемсерәп кенә куйган идем. «Халык» түгел, ә «әхлак» алмашу турында язган бит Тукай бик тә мәгълүм шигырендә. Кызганыч, кайсы авторның нинди язмасы булганын теркәп куймаганмын. Сүз иясе белән йөрми, дип уйлаганмындыр инде. Әмма алга таба «ияле» мисаллар күрерсез.

*«Иртә **белән***
кайнамакта бу базар:
Кайда баксаң, анда
тулган сәүдәгәр.
***Кайсы** сатмактадыр,*
кайсы ала,
Берсе алдый шунда,
берсе алдана».

Бу юллар «Мәдәни җомга» газетасының 2010 елгы 5 ноябрь санынннан, Сөембикә Кашапованың «Базарда хәтәр бар» дигән язмасыннан. Инде Тукайга кайтып карыйк. «Берлән» дигән сүзнең «белән» дип үзгәртелүенә бәйләнеп тормыйк, икесе дә бер сүз дип әйтергә була. Ә «кайсысы» сүзен (беренче килгәнен) «кайсы»га алмаштыру белән шигырьнең ритмикасы бөтенләй бозыла. Соңгы юлда исә өтер үз урынында түгел, Тукайда: *«Берсе алдый, шунда берсе алдана».* Юкка бәйләнә бу абзый, димәгез, өтернең дә мәгънәсе зур аның.

«Рәхәтләнеп китә
шунда җаным, тәнем,
Шуннан соң
дәртләремә
дәрман табам».

Бу юллар үзем бик ихтирам иткән зур галим Хатип Миңнегуловның «Китапта – гасырлар хитабы» дигән язмасыннан («Мәдәни җомга», 5 октябрь, 2012). Тукайда бит *«Шуннан гына дәртләремә дәрман табам».* Ритм да бозылган, мәгънәгә дә хилафлык килгән.

«Әлбәттә инде, аның өчен (М.Мәһдиев турында сүз бара. – **И.Б.**) иң олы шәхес, иҗатына мөкиббән киткән язучысы Габдулла Тукай булды. Сүзнең кадерен, төмен белгән кеше буларак, ул Тукайның бер җөмләсен, сүзен бозганны, алыштырып куйганны сизсә, ишетсә, җен ачулары чыга торган иде», – дип яза филология фәннәре докторы Тәлгат Галиуллин «Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы» дигән роман-эссесында («Казан утлары», №10, 2012, 83 бит). Ә үзе ике дә уйламый, боза, алыштырып куя.

Инде ун биткә алгарак кайтып, 73 нче биттән өзек китерик: *«Шигырьләрен яттан күп белсә дә, җае чыккан саен ул Тукайның «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» мәрсиясенең соңгы юлларын аерым бер басым ясап кабатларга ярата иде:*

Бармыни бездә чын
кеше кадерен белү?!
Без аны кайдан белик,
мискин үлеп
күрсәтмәгәч!».

Мөхәммәт Мәһдиев башкачарак кабатлагандыр дип әйтәсе килә, чөнки Тукаебыз үзе менә болай язган:

«Бармыни бездә
гомумән чын кеше
кадрен белү?!
Без аны кайдан белик,
мискин үлеп
аңлатмагач?!

(«Г.Тукай. Әсәрләр, биш томда – 2нче том, 209 бит).

Җамал Вәлидигә яраган безгә дә ярый, дип карыйлармы әллә хәзерге авторлар? «Казан утлары»ның быелгы 10нчы санында күренекле тел галименең 1923 елда язган «Тукайның шагыйрьлеге» дигән мәкаләсен баскаңнар. Узган гасыр галиме Тукай шигыреннән дип түбәндәге юлларны китергән икән:

«Бераз вакыт шатлык
таба исрек кенә.
Үз авызына
агу эчреп кенә»

Тукайның «Сәрләүхәсез» дигән шигырендә исә бу юллар башкачарак:

«Бераз вакыт шатлык
таба исрек кенә,
***Үз-үзенә ачы** агу*
эчреп кенә».

Җ.Вәлиди мәкаләсен укыганнан соң, ни дияргә дә белмичә аптыраште калаысың. Тукайны бозу традициясе яңа нәрсә түгел икән шул, су башыннан болгануын дәвам итә...

Алдан кисәтергә иде

Әлеге дә баягы, киңәш бирү теләге белән язам. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында 21 декабрь кичендә «Йөзек кашы» әсәрен күрергә насыйп булды миңа. Театрдан чыкканда күңелемне соклану хисләре генә биләде дип әйтә алмыйм. Фикерләремне сезгә дә җиткерим.

Ильяс САЛИХҖАН

Танылган язучы Фатих Хөсни әсәре ул. Режиссер Лилия Әхмәтова Илгиз Зәйниев инсценировкасы буенча куйган аны. Үзеннән-үзе сорау туды күңелдә: мәгълүм әсәрне сәхнәләштерү отышлы килеп чыктымы икән?

Авыл яшьләре күрсәтелде анда. Айдар һәм Вәсилә исемле егет белән кызның мәхәббәт тарихы дисәң дә ярый әлеге әсәрне. Аларның яшь чакларын күрәбез башта сәхнәдә. Әйтергә кирәк, бик тырышып уйнады артистлар яшүсмерләрне. Кызу-кискен хәрәкәтләре дә, артыйорты сүзләре дә нәкъ шул яшьтәгеләрнеке... Әмма нәрсәдер ышандырмый, нәрсәдер җитеп бетми кебек иде сәхнәдә. Хатхәбәрләр йөртүче Ниса түти һәм баш персонажның атасы белән әнисе сәхнәгә чыккач, барысы да аңлашылды. Менә бу өлкән геройларны уйнаучы өлкән артистлар шундук сәхнәне тутырды. Юк, алар ду килеп чабышып йөрмәделәр. Кыска гына вакытта ике-өч җөмлә әйтүләре дә житте – бөтен игътибарымны үзләренә җәлеп иттеләр... Әйе, яшүсмерләрне сәхнәдә күрсәтү җиңел түгел. Балигъ булмаган үсмерләр театр һәм, гомумән, әдәбият өчен отышлы тема түгел, дисәм, минем белән килешерсез дип уйлыйм. Ә бу сәхнәдә аларга, әйтер идем, артык күп вакыт бирелә. Киңәшем дә шул: баш геройларның 15 яшьтәге чаклары кыскартылып бирелсә, һичшиксез, спектакль отар иде.

Ул чагында сәхнә вакытын нәрсәгә сарыф итәргә соң, диярсез. Ә аңа мөмкинлек бар анда! Әйткәнемчә, төп вакыйга Айдар белән Вәсилә арасындагы мәхәббәт бит. Тик кайда соң ул хис? Айдар 15 яшендә гашыйк икән инде, аның дәвамы кайда? Югыйсә егет үсә, шахтада да эшләп дөнья күреп кайта, кызны беренче күргән көннән бернич ел вакыт уза... Егет белән кыз менә шулай җитлеккәч, алар арасындагы мөгамәләне җентекләп күрсәтү, һичшиксез, кызыклы булыр иде. Югыйсә, вакыйгалар бик күп, ә ике йөрәкнең үзәк вакыйга булырга тиешле мәхәббәте юк та кебек. Кайда соң ул? Ә Вәсилә кайда? Аның да хисләрен күрсәтү кирәктер бит инде. Мәсәлән, кай арада Вәсилә үзен урлатырга ризалыгын бирә? Гомумән, ни өчен качарга килешә соң әле ул? Беләбез бит инде: элекке заманда татар кызы әти-әнисе сүзеннән чыкса, ул – фаҗига!

И-и, нигә аптырарга инде, Фатих Хөсни әсәре буенча болай да барысы аңлашыла ич, диярсез, бәлки. Укымаган кеше нишләр? Ул чагында афишада да, «Йөзек кашы»ның төп вариантын укып керү мәҗбүри, дип кисәтергә иде.

Соңга калганга колакчын «гаепле»

Хуҗа Насретдин яраткан ишәген янында йөрткән сыман, без колакчыннардан (наушник) аерыла алмыйбыз. Автобуска керүгә, билетка акча капшыйсы урында, шул буталып беткән колакчыннарны чыгарып, сүтә башлыйбыз. Имеш, кондуктор көтеп торыр әле, эше шул ич! Килеп, арканы какканчы музыка тавышын тыңлый бирәсең. Аны кая ишетү ди?!

Алинә
МИННЕВӘЛИЕВА

Элек этендә дә, бетендә дә кәрәзле телефон дип шакката идек. Хәзер нәрсә? Транспорт эченә кергән әзмәвердәй абыйларның да колакларында шул колакчыннар ялтырый. Аның зарарын күптән онытык инде. Без мәктәптә белем алганда, укучылар колакларын аның ише белән «тутырмый» иде әле. Әмма 11 нче сыйныфта укыганда, тормыш иминлеге нигезләре укытучысының сыйныфташыма әйткән сүзләре әле дә хәтеремдә. «Колакчыннар аркылы музыканы бик кычкыртып тыңласаң, колагың зәгыйфьләнеп калуы бар», – дигән иде ул. Бу сүзләр онытылмаса да, заманнан артта калып булмый шул. Без дә тыңлыйбыз аны. Тик кайбер битарафлар яки үз-үзләрен кайгыртучылар кебек түгел инде. Алайса, бөтен автобусны дер селкетеп торган рок музыкасын арыпталып эштән яисә укудан кайтып килүче һәр кеше тыңларга мәҗбүр.

Шул колакчыннар «гаебе» аркасында, әле сәер очракларга да юлыгасың икән! Мин бер әйберне күз алдына китерә алмыйм. Ничек инде ул сине бөтен дөнья эзләп йөргәндә, син аннан качасың? Хәзер бер кызны төртеп күрсәтте. Астындагын алты ай эзләгән, дигәндәй, нәкъ безгә кирәкле кыз булып чыкты тагын. Колакчыннарындагы музыкасын шулкадәр акыртып тыңлаган ул, хәтта каршысында

рысын да тәфсилләп аңлатам.

Автовокзал каршына килеп туктаган автобуска энем белән «ялт» кына кереп утырдык. Кузгалырга ашыкмый гына бит транспорт дигәне! Ә без тизрәк өйгә юл тоту ягын чамалыйбыз. Шулчак микрофоннан Балык Бистәсе ягына кайтучы бер кызның исем-фамилиясен бертуктаусыз атый башладылар. Теге кыз килми генә бит! Вәт, мин әйтәм, әллә онытылып, йоклап ята инде бу?! Автобус тора, шофер кузгалырга уйламый да. Хәер, озакламый, бер пассажир теге кешене исеменнән таныды. «Әнә, шушы кыз түгелме?» – дип, шоферга торган автобусын да күрмәгән. Бөтен кеше аның исем-фамилиясен ишетсә дә, ул бөтенләй ишетмәгән! Ә кыз оялмады да. Берни дә булмагандай, балкып, автобуска килеп керде ул. Аны эзләмәгәннәр, диярсең! Әле ярый калдырып китмәделәр үзен. Ул көннең соңгы маршрутыннан да колак какса, колакчыннарын, ай-һай, озак тыңлар идеме икән?!

Автобуска утырырга берничә минут калганда, музыканы ничек шулай каты куеп була инде ул?! Ирексездән: «Менә автобус килер, менә килер», – дип көтеп торасың бит. Кая инде анда колакчыннарны актара башлау?!

Үз залларында биергә язсын

Рафаэль
САЛЬМУШЕВ

Татарстан җыр һәм бию ансамбленә – 75 ел. Шушы көннәрдә 75 еллык юбилеен бәйрәм итүче ансамбльне республиканың «визит карточкасы» дип йөртүләре хактыр да.

Чөнки халкыбызның, танылган композиторларыбызның моңлы җырлары, татарның дәртле һәм салмак биюләре, милли киемнәре аларда саклана. Моны танырга кирәк. Ансамбльнең тарихында күренекле җырчылар Ания Туишева, Нәфисә Васильева, Таһир Якупов, Шамил Әхмәтҗанов халык күңеленә җыр сәнгатенең моңнарын җиткерүчеләр булдылар.

Яраткан җырчым Таһир Якупов турында истәлекләр җыентыгы китабын төзи башлагач, кайбер билгеле шәхесләр каршы чыктылар. «Көнче күбәләкләр» дә табылды. Янәсе, без дә аны белә идек, без дә истәлекләр җыентыгы китабы төзегән булыр идек...

Мин Таһир җырлаган ансамбльгә килеп йөрдем, аның белән эшләгән җырчылар һәм ансамбль коллективы, залларда барган репетицияләр белән танышып, нәтиҗәләр ясадым.

Ансамбль коллективына барып йөргәндә, ансамбльнең хормейстры Венера Гәрәева иде. Хәзер дә эшләвен дәвам итә. Бик тәҗрибәле белгеч Венера ханым. Ул Таһир Якупов турында миңа күп мәгълүматлар бирде. Китап җыелды, өч мәртәбә яңартып чыгардым. Әлбәттә, җыр һәм бию ансамбленең тирән эчтәлекле тарихы бар, ул – барлык традицияләребезне һәм гореф-гадәтләребезне саклаучы бер аерым утрау. Ансамбльнең җитәкчесе Айрат Хәмитов коллективны бар яктан да саклый. Ул – яңа алымнар белән эшләргә ярата торган җитәкче.

Коллективның 90 процентын яшьләр тәшкил итә. Ансамбльнең барлык бизәкләрен дә санап чыгарга дип үземә максат куймадым. Тамашачы буларак, үз фикеремне генә әйтмәкче идем. Әгәр Г.Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе яңа концерт залына күчә калса, аларның залын Татарстан җыр һәм бию ансамбленә бирергә кирәк. Шундый атаклы коллективның үз концерт залы булырга тиештер бит. Әйе, булырга тиеш. Бәйрәмегез белән!

МӘГАРИФ

Узып киткән 2012 ел мәгариф өлкәсендә дә шактый саллы эз калдырды. Иң зур үзгәреш – «Мәгариф турында»гы законның яңартылуы. Илдәге белем бирү системасы белән азмы-күпме кызыксынучылар ел дәвамында әлеге закон проектын уттан алып суга салдылар. Ник дигәндә, аңлашылмаучанлыклар байтак иде.

Закон яңарды, тәртип үзгәрерме?

Фәнзилә МОСТАФИНА

Урта һәм югары белем тулысынча түләүле булырмы, укытучыларга тиешле ташламалар саклaнып калырмы, оптимальләштерү дулкыны дәвам итәрме – киң җәмәгатьчелекне борчыган мәсьәләләр моның белән генә бетми. Әле Татарстанның тагын бер баш бәласе бар бит: ул – татар телендә белем бирү.

2012 елның соңгы көннәрендә документ рәсми кысаларга кертелде. Президент В. Путин кул куйган «Мәгариф турында»гы закон быелның 1 гыйнварыннан гамәлдә санала.

2010 елда тәкъдим ителгән проект башта халык хөкеменә тапшырылган иде. Министрлык сайтында эленгән закон проектын укып, һәркем үз фикерен калдыра алды. Янәсе, закон халык ризалыгыннан башка кабул ителмәячәк. Сүз ирегe алган халык исә ялындырып тормады: проектның җитешсез якларын да тәртип күрсәтте, үз тәкъдимнәрен дә кертте. Хуш, күпчелекнең фикеренә колак салып, проектка үзгәрешләр кертелергә тиеш иде кебек.

Фото бизәү өчен бирелә

Алар кертелде, әлбәттә. Тик әллә халык фикерен ишетеп бетермәделәр шунда, әллә үзебез «халык» төшенчәсен дөрес аңламаганбыз – законнан тулысынча канәгать калучылар күренми әлегә. Хәер, мин үзем белгән халык турында гына сүз алып барам инде, «югарылар» фикерләрен уңгасулга чәчеп йөрми, интернет-форумнарда язып калдырмый бит.

Закон проекты тирәсендә ыгы-зыгы тудырган сәбәпләрнең берсе – урта белем түләүле була икән дигән сүз чыгу. Бөтен эшгамәлләре шуңа таба барган Дәүләт Думасы үзе үк халыкны болгатты. Атнага берничә дәрес кенә бушлай кала, калган фәннәрне укыйсы килсә, бала аена биш-алты мең сум түләргә тиеш була дигән имеш-мимеш ата-аналарны да, укучыларны да, укытучыларны да пошаманга салды. Баланы мәктәптә укыту болай да шактый чыгымлы, инде хәзер аена алты меңне дә чыгарып сала башласаң? Әле сүз урта мәктәп турында гына бара бит. Дөрес, яңа законда бушлай белем алу хокукы турындагы пункт сакланып калган. Тик бу мәсьәлә тирәсендә томан таралып бетмәгән әле, чөнки «Юк, урта белем бушлай булачак!» дип шартлатып җавап бирүче юк.

Укытучылар яңа законны өмет катыш ышаныч белән көттеләр. Өстәвенә соңгы арада РФ мәгариф һәм фән министры Д. Ливановның хезмәт хакын арттыру турында әйтелгән сүзләре дә бар бит. Тик законда «укытучының хезмәт хакы шул төбәктәге уртача хезмәт хакыннан ким булмаска тиеш» дигән гарантия күренми. Түрәләр бу мәсьәләдә җаваплылыкны өсләреннән төшерделәр. Имеш, финанс ягын һәр төбәк үзе кайгырта. Федераль законда акка кара белән язылмагач, ничек кайгыртылыр инде ул?!.

РФ Дәүләт Думасының мәгариф комитеты әгъзасы Илдар Гыйльметдинов матбугат очрашуы вакытында милли белем бирү турындагы фикерләрнең күбесе хаталы булуын билгеләп үткән иде. Депутат, мәктәпләрдә татар телен укыту мәсьәләсендә борчылырга кирәкми, дип тә тынычландырды. Яңа кабул ителгән законда «төбәкләрнең үз дәүләт телләрен укыту һәм өйрәнү РФнең дәүләт телен укытуны һәм өйрәнүне кысмаска тиеш» диелгән, ягъни республикаларда туган телне укыту рөхсәт ителә. Рус теле дәресенә зыян салмаганда, әлбәттә. Менә тагын аңлашылмаучанлык килеп чыга: берәүләр өчен гадәти булган хәлне икенчеләр рус телен кысу дип карарга мөмкин. Төгәлсезлеккә үз файдасына бора белүчеләр азмыни?!.

«Мәгариф турында»гы закон, илдәге белем бирү системасы кебек үк, болганчык килеп чыккан. Безгә ярап булмый инде анысы, тик яхшы якка үзгәрешләрне дә күрәсе килә бит. Алга барасы, камилләшәсе килә. Барабыздыр инде без алга, тик читтән караганда бер урында таптанып торган, ул гына да түгел, артка чигенгән кебек тоела шул...

Мәктәптә кино караячаклар

Якын арада мәктәптә укытылучы фәннәр исемлеге тагын бер дәрескә тулыланырга мөмкин. Әле узган ел ук Никита Михалков, урта белем бирү йортларында кино сәнгатен укытырга кирәк, дигән тәкъдим белән чыккан иде.

Хуплау адымнары күренә башлады. РФ Мәдәният министрлыгы мәктәптә карау өчен яраклы дип тапкан фильмнар исемлеген сайтка элде. Анда 100 картина урын алган.

Әйтергә кирәк, исемлекне төзүдә халык та катнаша алды. Интернеттагы махсус сайтта, җәмәгатьчелек үз фикерен калдырсын өчен, махсус бит булдырылган иде. Күп кенә мәктәпләрдә дә Михалковның идеясе буенча сөйләшүләр үтте. Яңа фән кертү турындагы тәкъдимгә кискен каршы төшүчеләр юк. Тик кимчелекле яклар булуын да онытмаска кирәк. Беренчедән, кино сәнгатен укучыга аңлата алырлык укытучылар бармы? Дөрес, бездә биология укытучысы – математика, физика мөгаллиме география укыткан очраклар җитәрлек анысы. Быел өстәлгән дини мәдәният һәм әхлак нигезләре фәнен дә махсус шул тармак буенча белеме булмаган укытучыларга ышанып тапшырдылар бит. Тик кино ул уен-муен түгел. Исемлектә күбесенчә тарихи һәм Бөек Ватан сугышына кагылышлы картиналар урын алуын да исәпкә алсак, мөгаллимнәргә шактый тирләп пешәргә туры килмәгәе.

Икенче минус – яңа фән искеләрен кысрыклаячак. Һаман да шул әдәбият, рәсем яки музыка кебек икенче планда йөргән фәннәр зыян күрер инде.

Исемлекне кино белгечләре төзегәнлеге сизелә. Ник дигәндә, мәктәп яшендәге балага кабул итәргә шактый катлаулы булган картиналар да очрый биредә. Мәсәлән, «Понизовая вольница» дип аталган беренче сүзсез фильмны бөтен бала да аңлый алырмы? «Месть кинематографического оператора» укучыларда кызыксыну уятырмы? Ахыргача хәл итеп бетерәсе мәсьәләләр бар әле.

100 фильм арасында «А зори здесь тихие», «Белое солнце пустыни», «Берегись автомобиля», «Бриллиантовая рука», «Война и мир», «Молодая гвардия», «Чук и Гек», «Я шагаю по Москве» һәм «В бой идут одни старики» кебек халык мәхәббәтен яулаган картиналар да бар.

Укырга — Малайзиягә

Ниһаять, ике атналык каникулда көч туплаган укучылар һәм студентлар яңадан белем гранитын кимерергә кереште. Соңгылары кеше рәтеннән ял итүләре белән Универсиадага бурычлы. Югыйсә моңарчы каникуллары гыйнвар ахыры-февраль башына туры килә иде бит. Зур спорт ярышы көтелгәнлектән, Казан вузларында уку елы кыскарды. Яңа елга кадәр студентлар беренче сессияне япты, икенчесе исә май урталарында төгәлләнәчәк. Тизләтелгән программа буенча уку студентларга ошап бетмәсә дә, имтиханнарны Яңа елга кадәр тапшырып ялга китүне күпләр хуплады.

Татарстан студентлары ял иткән арада, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Малайзиянең югары белем бирү министры Дато Сери Мохамед Халед Нордином белән очрашып, хезмәттәшлек турында килешергә өлгерде. Илбашының билгеләп үтүенчә, үзара студентлар алмашу башка өлкәләрдә дә үсешкә китерәчәк.

Бүген Россия вузларында Малайзиядән килгән өч мең студент белем ала икән. Шуларның өчесе генә Казанда – Казан дәүләт медицина университетында укый. Президент бу санны арттыруның мөһимлеген билгеләп үтте. Бездәге Россия ислам университетыннан дүрт студент Малайзиядәге Халыкара ислам университетында белем эсти. «Алгарыш» программасы нигезендә, студентлар һәм аспирантларны чит илгә тагын укырга җибәрү мөмкинлеге бар.

«Июльдә бездә Универсиада узачак. Сезнең студентлар да анда катнашырлар, Казанның йөзен күрерләр, мондагы шартлар белән танышырлар, дип уйлыйм», – диде Рөстәм Миңнеханов министрга мөрәҗәгатендә. Үз чиратында, Малайзия министры да бик теләп хезмәттәшлек итәчәкләрен белдерде.

Педагоглар тәҗрибә уртаклашты

Сөембикә БИЛАЛОВА

Киңәшле эш таркалмый, диләр. Мәгариф өлкәсенә дә кагыла бу сүзләр. Яңа ел алдыннан Казанда тагын бер зур тәҗрибә уртаклашу чарасы булып узды.

Автор фотосы

«Педагогик белем бирү: тарих, бүгенге заман, перспективалар» дип аталган II Халыкара фәнни-гамәли конференциясендә Татарстан, Казахстан һәм Үзбәкстан республикаларыннан, Болгариядән, Россиянең Мәскәү, Екатеринбург һәм башка шәһәрләреннән вәкилләр катнашты.

Конференциянең төп максаты тәҗрибә уртаклашу, Россия һәм чит төбәкләрдәге белем бирү системасының үсеше турында фикер алышу иде. Ә урта салып сөйләшерлек, көн үзәгендә торган мәсьәләләр аз түгел. Чарада белем бирүнең психологик һәм педагогик алымнары, белгечләр әзерләү, фәннәрне укыту методикасы, тәрбия, белем бирү системасы белән идарә итү кебек темалар каралды. 16 нчы татар-инглиз гимназиясе базасында узган конференциядә педагогика фәннәре докторы, профессор Рөстәм Маликов җитәкчелек итте. Доклад белән чыгыш ясаучыларның белем бирү өлкәсендә югары дәрәҗәләргә ирешкән белгечләр булуын да әйтеп китәргә кирәк.

Татарстанда укытучының роле турында да шактый фикерләр әйтелде биредә. Күзгә күренеп торган проблемалар җитәрлек: тиешле күләмдә финанслау, педагогларның һөнәри үсешен күзәтчелек итүче бердәм система юк, яңа гына вуз тәмамлаган укытучыларны белем бирү йортларына тарту тиешенчә оештырылмаган, күпчелек мөгаллимнәр яңа ысуллар кулланып эшләүне кирәк санамый. Конференциядә катнашучылар ТР Мәгариф һәм фән министрлыгына даими рәвештә белем бирүнең сыйфатын тикшерүне оештырырга, яшь педагогларны эшкә җәлеп итү чараларын арттырырга тәкъдим итте.

Сәхифәне Фәнзилә МОСТАФИНА әзерләде

СӘНГАТЬ ӘХРАМЫ

Бу арада бер төркем рәссамнар – Лада Аюдаг, Фәрит Вәлиуллин, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе Рифкат Вахитов, Елена Габдрахманова, Татьяна Никашина, Татьяна Тэнч, Ирина Краснова-Волгина һәм яшь дизайнер Марат Аюпов Парижда узган «Татарстан күге астында» дип аталган күргәзмә тәэсирендә яшидер, мөгаен.

ПАРИЖ, ПАРИЖ...

КҮРГӘЗМӘ

Расиха ФӘИЗОВА

Францияне, Парижны күрү, Эйфель манарасы кебек билгеле урыннарда 2013 елда Казанда узачак иң төп вакыйга – Универсиаданы тәкъдир итү йөзеннән Универсиада әләмнәре белән урамнардан узу, бергәләп фотосурәтләргә төшү – болар һәммәсе мөһим. Әмма рәссамнарыбызны тәэсирләндергән төп вакыйгалар чыннан да күргәзмәләр эргәсендә була. Шунысын да әйтергә кирәк, «Татарстан күге астында» дип исемләнгән бу экспозиция «Казан – Россиянең өченче башкаласы» дигән проектны йомгаклаучы күргәзмә буларак та игътибарга лаек. «Әлеге проект 2010 елның декабрендә Прагада старт алган иде. Узган елның июлендә ул Вашингтонда дәвам итте һәм аны йомгаклау өчен Парижны сайлау шулай ук очраклы түгел. Бу – Универсиада уты кабынган урын», – ди күргәзмәнең кураторы, БДБ Рәссамнары һөнәри берлегенең Казан бүлекчәсе рәисе Лада Аюдаг. Йомгаклау чарасы булса да, Парижга янәдән юллары төшәргә охшап тора рәссамнарның. Чөнки иң мөһиме – күргәзмәләр барышында татар мәдәнияте, тарихы белән кызыксыну барлыгын күрә рәссамнар. Шуңа күрә дә Франция башкаласыннан бер-бер артлы дүрт эшлекле тәкъдим белән кайтты алар Казанга. Рудольф Нуриевның тууына 75 еллыгына ачылачак музейда, мэриядә, Россия илчелегендә янә күргәзмәләр ясарга чакыралар. Күргәзмәгә килүчеләр арасында хәтта Сабан туе күренеше сурәтләнгән картинага төртеп: «Әнә шунда буласым килә», – диючеләр дә була.

– Беренче экспозиция Парижның иң борынгы китапханәләренең берсе булган Тургенев исемендәге китапханәдә күрсәтелде. Ачылышта Париж мэриясының халыкара бүлек җитәкчесе, барлык ассоциацияләр мөдире Пьер Шапиру, Париж тәнкыйтьчеләренең халыкара ассоциациясе рәисе Виктор Игнатьев, Елена Мякотина-Каплан рәислегендә китапханәнең әтрафлы әгъзалары, Париж-Сорбонна университетының профессор Елена Бестужева кебек билгеле шәхесләр катнашты. Парижда яшәүче рус интеллигенциясе вәкилләренең дәррәү килеп әлеге чарада катнашуы көтелмәгән сюрприз булды. Безнең Казанда мондый хәл күзәтелми. Һәммәсе күргәзмәнең югары дәрәҗәдә булуын билгеләп үтте. Шәхсән үземә иң кызыгы Мәскәүдә Суриков исемендәге институтта бергә укыган сабакташым, татар егете Ринат Анимаев белән очрашу булды. 1989 елдан бирле Парижда яши икән. Сынлы сәнгать тәнкыйтьчеләре фикере буенча, ул Франциянең иң яхшы 10 рәссамы исәбендә бүген. (Р.Анимаевның бабалары узган гасырның 30нчы елларында Татарстаннан Урта Азиягә күченеп киткән булган. Фамилиялләрен алыштырганнар.) Ул, чын сәнгать чикләрне белми, дип, рәссамыбызның эшләре турында бик матур сүзләр әйтте, – ди КФУның сынлы сәнгать һәм дизайн кафедрасы доценты Фәрит Вәлиуллин, тәэсирләре белән уртаклашып.

Күргәзмә эшен Россиянең фән һәм мәдәният үзәгендә дәвам итә. Ачылыш Франциянең фән һәм мәдәният өлкәсендәге мактаулы әһелләре катнашында узды.

– Күргәзмәне Россия үзәге директоры Игорь Шпынов ачты. Ул нәкъ бер ел элек биредә ТРның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев булуын билгеләп үтте. Минтимир Шәрипович та мәдәниятләр диалогы хакында сүз алып барган булган. Һәм әлеге экспозициянең аның сүзләренә бер дәлил булып торуын ассызыкладылар. Мондый җылы очрашулар, булса да, бик сирәк була торгандыр. Сөйләшеп сүзләребез бетмәде. Чөнки араларында Казанда Державинга багышлап уздырылган конференциядә катнашучылар да бар иде. Казанны сораштыралар. Узган елның 9 декабрендә генә Рөстәм Миңнехановның рәсми визит белән Франциядә булып китүенең дә йогынтысы зур иде. Чәк-чәк белән чәй эчә-эчә, дүрт сәгать ярым вакыт үтеп киткәнен сизми дә калганбыз, – ди Лада Аюдаг.

Әлбәттә, тәэсирләр моның белән генә чикләнми. Толстой нәселенең дәвамчылары белән очрашу да; Әлмәт егете, 17 ел инде Парижда яшәүче – Сотбиз аукционы арт-дилеры Ленар Гәрәев белән аралашу да олы бер вакыйга була рәссамнар өчен.

Тумышы белән Ютазы районының Көрәш-Бүләк авылыннан булса да, тормышын Лениногорск каласы белән бәйләгән Мәгъшия ханым. Дөрес, авылда колхоз рәисе, бухгалтер, зоотехник булып эшләгән әтисе кебек, язмышын авылга багышларга да исәбе булмый түгел кызның.

Башларга беркайчан да соң түгел

ОСТАЗ

Ютазыда урта мәктәпне тәмамлауга, ике ел авылда гади колхозчы булып йөрер идеме юкса?! Әмма күңелгә салынган иҗат оеткысы барыбер үзенекен итә – ул Чабаксар педагогия институтының худграф бүлегенә читтән торып укырга керә. Инде Лениногорск педагогия көллиятендә эшли башлавына да тиздән 40 ел. Бүгенге көндә шәхси тупланмасында 300 ләп эше саклануга карамастан, Мәгъшия Мөбарәк кызы, тормышындагы иң мөһим эше, дип, Мәснәви Хәйретдинов җитәкчелегендә Лениногорск балалар сәнгать мәктәбен оештыруда катнашып йөргән елларын атый.

Әле бүген дә булачак укытучыларга сынлы сәнгать, рәсем, композиция укытып йөрүче хезмәт ветераны, РФ урта махсус мәгариф системасының мактаулы хезмәткәре Мәгъшия Мөхәммәтова белән аның 74 эштән торган шәхси күргәзмәсе эргәсендә очраштык. Моңа кадәр дә күп тапкырлар Лениногорск, Бөгелмә, Баулы, Җәлил һәм Актүбәдә

шәхси күргәзмәләрен уздырган рәссам янә иҗатына хисап тота. М.Мөхәммәтова – үзен пейзажда тапкан рәссам. Иҗат егәрен табигать белән бергә бер калып аралашудан ала ул. Моңа кадәр майлы буяулар, акварель белән эшләгән ханым соңгы 2 елда ныклап торып графикага тотынган. Күргәзмәсендә аеруча игътибар яулаган эшләре дә шулар түгелме икән әле?! Акка кара белән ташка баскан кебек алар. Үзе өрфиядәй җиңел. Ник бер артык сызык булсын! «Мин инде иҗаттан башка яши дә алмыйм. Челтәр үргән кебек, үзеннән-үзе бара ул, – ди рәссам эш алымын аңлатырга теләгәндәй. – Тик шунысы кызганыч – хәзер яшьләрнең иҗат белән утырырга әллә ни вакытлары юк. Кәгазь боткасы басып китте аларны», – дип зарланып та алды әле.

Рәссам, барыннан да бигрәк, табигатьнең алмашынучан халәтенең драмасына үтеп керә ала («Яңгыр алдыннан», «Әнгер-меңгер көн»). Ярата ул шундый мизгелләрне. Тотып та ала, шуны тыгыз, катлаулы төсмерләр белән бирә дә белә («Көзге кич»). Авторның барлык натюрмортларын җыйсаң, аларын «Җәйге кәеф» дип атап булыр иде, – ди Мәгъшия ханымның иҗаты турында сәнгать белгече Н.Горюнова.

Бу, әлбәттә, тормышны яратудан, гади генә әйберне дә җырлап торган шигърияткә әверелдерә алудан килә. Озак еллар үзе тәрбияләп үстергән этләре турындагы кыйссаларны тыңлаганда да моның шулай булуына янә инанасың.

«Кышкы вернисаж»

Табигать галиҗәнапларыннан да тылсымлырак, талымлырак рәссам булырмы?! Йолдыз системасындагы бер генә планетада да безнең Җирдәге кебек акылга сыймаслык җете пейзажлар юк.

КҮРМИ КАЛМА

Ел фасылы алышынган саен, табигать җиребезне төрле төсләргә мана.

Беренче карашка, кышкы палитра әллә ни бай түгел дә кебек. Шуңа да карамастан, кышын өстенлек иткән ак, соры һәм кара төсләр – ул үзе бер әкияти дөнья, үзе бер тамаша. Ябалак-ябалак яуган карның җиргә төшкәнен күзәткәнең йә булмаса, кояш яктысында күзләрне әлҗе-мәлҗе китерә-китерә җиргә түшәлгән «энҗе-мәрҗәннәргә», агач ботакларына сырышкан энәдәй бәсләргә карап хозурланганың булдымы әле быел? Бу ыгы-зыгылы дөньяда кая инде вакыт булсын, дисезме? Йә, соң, тукталыйк бер мизгелгә! Әнә, буран салып киткән кар көртләрен генә күр: маһир сынчы кебек койган да куйган бит!..

...БДБ Рәссамнары һөнәри берлегенең Казан бүлекчәсе эшчәнлегенең 10 еллыгына багышланган «Кышкы вернисаж» күргәзмәсе дә туган җиребезнең кышкы хозурлыгына мәдхия укый. ТР Милли музеенда ачылган әлеге күргәзмә 7 февральгә кадәр эшләячәк.

ТЕЛ — юмалаучыга да корал, дуамалчыга да

Һиндстан рәссамы Ани Кей борын, терсәк, маңгай белән рәсем ясап караганнан соң, картиналар язу өчен тел иң кулае дигән нәтиҗәгә килгән.

СӘЕРЛӘР

Буяу белән эшләү баш авырту, күңел болгану кебек билгеле бер дәрәҗәдәге кыенлыклар тудырса да, «бу ысул белән эшләүче әлегә мин генә» дигән фикер, күрәсең, уеннан кире кайтырга ирек бирми торгандыр.

Рәссам тора-бара буяуларга иммунитет барлыкка килүенә өмет итә. Аның «яланган» эшләре арасында Леонардо да Винчиның бер картинасының күчермәсе дә бар. Киңлеге 2,4 метр булган ул эшне 5 ай дәвамында ялый рәссам. Үзе эшләгән сынлы сәнгать институтының җитәкчелеге ризалык биргән очракта, тел белән эш итү алымнарын студентларына да өйрәтмәкче Ани Кей.

Сәхифәне Расиха ФӘИЗОВА әзерләде

СӘЛАМӘТЛЕК

Катаракта яшьләрдә дә очрый

Олыгая барган саен, кешенең тормыш тәҗрибәсе генә артып калмыйча, организмында да төрле физиологик үзгәрешләр барлыкка килә. Шул исәптән, күрү органы булган күзләрдә дә. Алар белән бәйле иң киң таралган авыруларның берсе – катаракта. Катаракта ни сәбәпле барлыкка килә? Аңардан бары тик операция ясатып кына котылып буламы? Әлеге сораулар белән без табиб-офтальмохирург, медицина фәннәре кандидаты Гүзәл Фәрит кызы ХАФИЗОВАга мөрәҗәгать иттек.

ТАБИБ СҮЗЕ

Дилбәр ГАРИФ

– Гүзәл ханым, катаракта нәрсә ул?

– Катаракта ул – күз ясмыгының (хрусталикның) томалануы. Катаракта вакытында күзнең күрү сәләте начарая, сурәтләр ачык күренми, томан яки полиэтилен пленка аша күренгән кебек була. Ул, гадәттә, 55-60 яшьтән олырак кешеләрдә күзәтелә.

– Катаракта яшь олыгаю белән генә бәйлеме?

– Юк. Соңгы вакытта 40-45 яшьлекләр дә күп мөрәҗәгать итә башлады. Химия производствосында эшләүчеләрдә дә күзәтелә. Төрле зарарлы факторлар, травмалар да катаракта барлыкка килүгә сәбәпче булып тора. Ул хәтта кечкенә балаларда тумыштан да очрый.

Россиядә елына якынча 350 мең кешегә ясалма ясмык куела.

– Аны, нинди дә булса чаралар күреп, булдырмый калырга мөмкинме?

– Катарактадан махсус дарулар булмаган кебек, махсус профилактика чаралары да юк. Күзгә тамыза торган витаминлы препаратлар ярдәмендә күз ясмыгын тукландырырга, андагы алмашу процессын яхшыртырга, башлангыч этапта катарактаның үсеш алуын тоткарларга, операция вакытын кичектереп торырга була анысы. Әмма иртәме-соңмы, катаракта проблемасын хирургия юлы белән хәл итми булмый. Чөнки бернинди дару да томаланган күз ясмыгын үтәкүренмәле итә алмый. Операция барышында аны алып, ясалма ясмык куябыз. Кызганыч, катарактаның башланганын табибка баргач кына беләләр. Шуңа да елга бер тапкыр күз табибына күренеп торырга кирәк.

– Катарактаның «өлгергәнен» көтеп торырга кирәкме?

– Юк. Хәзерге технологияләр белән башлангыч стадиядә дә операция ясарга була. Иртәрәк мөрәҗәгать итсәң, нәтиҗәсе дә яхшырак.

Грек теленнән тәрҗемә иткәндә, катаракта шарлавык дигән сүз. Бу атама аңа катаракта белән авырган кеше әйберне элпә аша күргән кебек булганга бирелгән.

– Ясалма ясмыкны ничә яшькә кадәрге кешеләргә куясыз?

– Яшьнең чиге юк. Бездә хәтта 103 яшьлек пациентка да куелды. Анализлары яхшы булса, терапевт рөхсәт бирсә, пациентның яшенә карамыйбыз.

– Операциягә барыр алдыннан нинди анализлар бирергә кирәк?

– Гомуми кан һәм сидек анализлары, РВ, ВИЧ һәм гепатитка анализлар, флюорография нәтиҗәсе, оториноларинголог (ЛОР) тикшерүе, терапевт рөхсәте кирәк.

– Операциядән соң, табибка ничә тапкыр күренергә?

– Өч ай дәвамында. Пациент ике-өч атна буе ялкынсынуга каршы дарулар тамыза. Ике ай авыр физик эшләр эшләргә ярамый, туңудан сакланырга кирәк.

– Операция ясату күпме тора? Ул бәягә нәрсәләр керә?

– Бәясе пациент сайлый торган ясмыктан тора. Эконом вариант 19 мең, яхшырагы 27-29 мең, премиум класс дигәне 50 меңгә якын. Моңа табиб күрсәткән хезмәт тә, аңа тикшеренергә килү дә, операциядән соң күзгә тамызырга бирелә торган дарулар да керә.

– Ясалма ясмыкның яраклылык вакыты ничә ел?

– Аны җитештерүчеләр, сиксән елга исәпләнгән, дип ышандыра.

АЧЫКЛАУ

Минус белән плюс арасында ничек бирешмәскә?

Әле 20 градус салкын, әле 3 градус җылы... Һава торышы төрлечә кыландыра. Температураның болай кисәк кенә сикерүләре сәламәтлеккә генә уңай тәэсир итми. Нәкъ менә шундый көннәрдә баш авыртулары көчәя, буыннар сызлый башлый, инфаркт, инсультлар да мондый көннәрдә бермә-бер арта. Йөрәк-кан тамырлары авырулары булганнарга температураның кисәк кенә шулай сикерүләре зур сынау булып тора. Хәер, сау-сәламәт кеше дә әле аны бик авыр уздырып җибәрә. Бу вакытта нишләргә һәм сәламәтлекне ничек сакларга? Медицина хезмәткәре Валентина СПИРИДОНОВАдан киңәшләр сорадык.



– Сәламәтлегеннән зарланмаган кеше табигатьтәге мондый үзгәрешләрне әллә ни тоймаска да мөмкин әле. Бу көннәрдә күп вакытта өлкән яшьтәге апа-абыйлар һәм хроник авырулары булганнар азаплана. Бу, чыннан да, сәламәтлеккә нык тәэсир итә. Нишләргә дигәндә, төп киңәшләрнең берсе – тоз һәм составында тоз күп булган продуктларны, мәсәлән, казылык һ.б.ны ашауны киметү. Шулай ук спиртлы эчемлекләр эчү катгый тыела. Күбрәк ял итәргә һәм иртәрәк йокларга ятарга киңәш ителә. Ә актив тормыш алып баручылар һава температурасы кисәк уйнаган көннәрдә физик нагрузкаларны киметсеннәр иде. Аннары көндәлек стресслар да организмны бик нык талчыктыра, шуңа күрә, андый ситуацияләрдән дә саклануыгыз хәерле. Барлык киңәшләрне дә үтәгән очракта, табигать торышы гына сезне аяктан ега алмас.

«Куанычымнан елыйм»

Күптәннән бик каты авыручы абыем белән Казанга хастаханәгә дип чыгып киттек. Үпкәсен тулысынча тикшертергә куштылар. Рентгенга чират торабыз шулай. Барысы да диярлекябык, хәлсез кешеләр, шуңа әллә ничек, авыр булып китте.

МӨНӘСӘБӘТ

Энже ЯКУПОВА

Шулчак күзем бер читтә утыручы матур гына хатынга төште. Түгәрәк, чиста йөзле, карап торышка сау-сәламәт кебек күренүче бу хатын да авырыймы икәнни соң, дип эчемнән генә үз-үземә сорау бирәм.

Безнең чират әле соңрак. Шуңа да, ирексездән, бер-бер артлы кабинетка кереп киткән кешеләрне тикшереп утырырга туры килә. Менә чират теге матур хатынга да җитте. Кыюсыз гына бүлмәгә кереп китте ул. Озак та үтмәде, кире борылып чыкты. Йөзе кызарган, үзен тотышларын аңлатып булмый. Кулындагы кәгазь һәм рәсемнәрен кая куярга белми. Шул арада теге хатын янәшә бүлмәнең ишегенә сөялде дә елап та җибәрде. Безгә – чиратта торучы барлык кешеләргә дә, уңайсыз иде бу минутларда. Барыбыз да, кадаклангандай, урыннарыбызда утырып калдык, авырсынып, күзләребезне түбән төшердек.

Алай да түзмәдем, елап торучы хатын янына килеп, аның иңнәренә җиңелчә генә кагылдым. Ул, шуны гына көткән диярсең, яшьле күзләрен тутырып миңа карады да елмаеп куйды. Аннан соң, елаганы өчен уңайсызланган кебек, күз яшьләрен сөртеп алды да, барыбыз да ишетерлек итеп: «Гафу итегез, куанычымнан елыйм», – дип әйтеп куйды.

Бактың исә, республикабызның бер районыннан килгән бу хатын табиблар ялгышлыгы аркасында инде өченче аен газап чигә икән. Үз районнарында елга бер тапкыр үтелергә тиешле тикшеренүне узгач, аңа: «Үпкәңдә нидер бар кебек тоела», – дип хәбәр иткәннәр һәм яңадән тикшеренү үтәргә чакырганнар. Куркып калган хатын шундук хастаханәгә чапкан. Әмма үпкәсендә ул-бу күренмәгән. «Болай гына тынычланма әле, яман шешләрне тикшерүче хастаханәгә бар, шунда күрен», – дип, аны Казанга озатканнар. Яшәвенең бөтен ямен-тәмен югалткан хатын алар сүзен тыңлаган. Тик анда тикшеренү дә үпкәсенең чиста икәнлеген раслаган. Районга кайтып, андагы табибларга бу хакта әйткәч, тегеләре: «Кулыңдагы сурәттә нидер күренә бит. Кабат Казанга, икенче хастаханәгә, зуррак тикшеренүгә бар», – дип озатканнар. «Гаиләм, әти-әни, ирем, балаларым, үзем борчылып, ашаудан калдык, тилегә чыгабыз бугай инде дип торабыз», – ди бу хатын.

Һәм менә, ниһаять, бүген ул иң зур тикшеренүен үткән. Анда да табиблар үпкәсенең сау-сәламәт икәнлеген раслаган. Әлеге хатынның үзе белән районнан алып килгән рентген сурәтен караганнан соң, биредәге табиб, берни дә аңышмыйча, бик аптыраган һәм шул район хастаханәсе белән элемтәгә кергән. Ә андагылары исә үзләренең бик зур ялгышлык җибәрүләрен, икенче кешенең сурәте белән бутауларын аңлатканнар.

Ишек төбенә чыгып елаган хатынны аңладык шулай. Ул чарасызлыктан да, авырмавын белү шатлыгыннан да күз яшьләрен тыя алмады. Дөрес, табибларга булган ачуы да чиктән ашкан иде.

– Шундый хата җибәреп, безнең бөтен тынычлыгыбызны алган ул кешеләргә мин бик ачулымын, – диде ул. – Кайтуга, үзләрен судка бирергә телим.

Табиб хәтле табибларның шуның кадәр ваемсыз булуларын берничек тә аклап булмый...

Сәхифәне Чулпан НӘҖИПОВА әзерләде

АВТОМОБИЛЬ ДӨНЬЯСЫНДА

КЫШКЫ ЮЛДА САК БУЛ!

Җәе – җәй, кышы кыш булганда ни әйттең булыр иде дә, әмма быелгысы кебек бер җылытып, бер суытып торган кыш машина йөртүчеләр өчен аерым мәшәкатьләр тудыра. Суыкларда юллар бозлардан ачылып бетте дигәндә генә, тагын кар явып китә, һава җылынып, юлларда бозлавык барлыкка килә. Кышкы юлларда күңелсез хәлләргә юлыкмас өчен, машинага игътибарны арттырырга кирәк. Төрле һава шартларында идарә итү осталыгыгыздан чыгып, руль артына утыру-утырмауны да уйлап хәл итегез.

Туристлар төнлә автобуста баралар. Тау төшкәндә автобус, тизлекне арттырып, торган саен ныграк тизләнеш ала башлый. Пассажирлар куркынышалар, берсе озата баручы гидка әйтә:

– Автобус йөртүчегә әйтегез әле, бераз акрынрак барсын!

– Т-с-с, ярамый, әгәр мин аны уятсам, ул мине бәреп үтерә...

Бозлы юлда йөргәндә машина шиннары ашалмаган булырга тиеш. Кыш көне тәгәрмәчләр буш булмасын, салкында резинаның ярылганын истән чыгармагыз.

Карлы юлда машина шуып, уйнаклап киткән очракта рульне кискен боргаларга, педальләргә кинәт баскаларга кирәкми. Бер үк вакытта тормоз педаленә басып, кинәт рульне бору шулай ук куркыныч. Кыш көне тормозларны яхшылап тикшерергә кирәк, бөтен тәгәрмәчләр дә берьюлы туктатылырга тиеш.

Бозда машинаны туктату өчен, тормозларны бөтенләй кулланырга кирәкми, аларны машина туктап җиткәндә генә эшкә җигеп була. Тормозга басу, файдасыз гына түгел, куркыныч та. Мәгълүм булганча, тормозлар белән файдалана белүенә карап, машина йөртүченең осталыгын билгелиләр. Хәрәкәт режимын яхшы белүче тормозга сирәгрәк һәм салмаграк баса.

«Энәле» (шиплы) шиннар кирәкме? Бик тайгак юлдан хәрәкәт иткәндә, еш кына машина йөртүче аны тыя алмаганын сизә. Сәбәбе гади – тәгәрмәчләрнең хәрәкәт юнәлеше белән юл үзе идарә итә.

Юлдагы боз, кар машинаны читкә җибәрергә сәбәпче булып тора. Бу очракта рульне боргаларга кирәкми, бераз көтәргә киңәш ителә. Бозлы урынны узгач, машина сез теләгән полосага басачак һәм элеккечә тигез хәрәкәт итәчәк. Мондый урыннарда машина йөртүчеләр дулкынлана башлый, югалып кала, алар моның сәбәбен юлдан түгел, машинадан күрә. Бу очракта «энәле» шиннар ышанычны арттыра һәм машина йөртүчене тынычландыра.

Салымнар арта

Көн үзәгендә такси акрын гына бөкедә бара. Бик нык ашыккан пассажир, түземе бетеп, сорап куя:

– Әйтегез әле, бераз тизрәк бара алмыйсызмы?

– Бара алам, ләкин безгә машинаны калдырып китәргә рөхсәт итмиләр...

Ел башыннан транспорт салымы артачак. Бу соңгы сигез елда беренче тапкыр һәм 13 процент тәшкил итәчәк. Беренче чиратта ул двигательнең егәрлегенә карап түгел, машиналарның авырлыгына карап артачак. Шулай ук кайбер ташламалар да бетереләчәк. Моңа хәтле Россия Президенты, транспорт салымнарын гадиләштерергә кирәк, дип белдергән иде, әмма бу юнәлештә әлегә берни дә билгеле түгел. Дөрес, салымнарның артуы әлегә Мәскәүдә генә булачак.

Бер ат көченә салым якынча 5-8 сумга арта. Барыннан да бигрәк моны 100 ат көченнән азрак егәрлеге булган машина хуҗалары сизәчәк. Мондый машиналар – Chevrolet Lacetti, Renault Logan, Daewoo Nexia, шулай ук Lada ның барлык модельләре. Элек бу машина хуҗалары бер ат көченә 7 сум түләсә, хәзер аның күләме 12 сум булачак. Мисал өчен, Элек Lada Priora өчен 630 сум түләнсә, хәзер салым 1080 сум тәшкил итә.

Егәрлеге күбрәк булган машиналар өчен салым күләме элеккечә калачак. 200-225 һәм 225-250 егәрлекле машиналарга салым бер ат көченә 75 һәм 100 сум туры килә.

Моңардан тыш, салымны ташламалы режимда карау егәрлеге дә үзгәргән. Машинаның егәрлеге 200 ат көченнән арткан очракта ташламадан файдаланып була, ягъни аның хуҗасы салымнардан азат ителә. Ташламалардан хәрби хәрәкәтләр ветераннары һәм инвалидлары, инвалид баланың ата-анасы, радиация тәэсиренә дучар ителгәннәр һәм күп балалы гаиләләр файдалана ала.

Узган елның азагында Президент салымнарны тулысынча бетерергә дигән иде. Ул барысын да ягулык акцизына күчерергә тәкъдим итте: күпме йөрисең – шуның хәтле түлисең. Аңа хәтле шундый ук башлангыч ягулык бәяләрен күтәрүгә китерде, әмма салым бетерелмәгән иде.

«АЛТЫН» машина өчен миллион гривен

Maserati Granturismo машинасы дөньяда берничә генә. Шуларның берсе 2011 елда Одессага килеп эләгә. Хәзер исә аны хуҗасы бер миллион гривенга (115 мең доллар) сатарга җыена. 2008 елгы әлеге машина 5 елга нибары 36 мең км юл узган. Аның шундый кыйммәт булуының сәбәбе – ул алтын төсендәге пленка белән капланган. Билгеле, аның составында берминди алтын юк, әмма алтын төсендәге тюнингка карап, күпләрнең исе китә.

«Алтын» Maseratiның хуҗасы исем-фамилиясен атамый, ул – чит ил чыгышлы Одесса бизнесмены.

Сез беләсезме?

√ Машина шиннары күп очракта сәгатенә 80 км тизлек белән барганда тишелә.

√ Тәгәрмәчләрдәге басым нормадан түбәнрәк булган саен, ягулык күбрәк бетә.

√ 3/4 максималь тизлек белән йөргәндә ягулык азрак тотыла.

√ Һәрбер җилләнеп йөрергә яратучы, вакытны янга калдырам, дип акланырга тырыша. Исегездә тотыгыз: тизлекне сәгатенә 40 чакрымнан 50гә арттырганда, сез 100 чакрым араны ярты сәгатькә тизрәк үтсәсез, ә 90нан 100гә арттырганда һәр 100 чакрымга вакыт «экономиясе» нибары 7 минут кына була. Уйлап карагыз әле: җиде минут өчен үзегезне һәм башкаларны куркыныч астына куярга кирәкме икән? Сак булыгыз!

Түбәндәге таблицада өске колонкада – спидометр күрсәткече, уртадагы һәм аскы колонкаларда – тормозга басканнан соң машинаның күпме юл үтүе күрсәтелгән (метрларда). Уртадагы колонкада – яхшы һава торышы булганда, ә аста – киресенчә. Бу саннарга җәяүлеләр дә күз салсын иде.

– Нигә сул як поворотнигыгызны гел кабызып йөрисез? – дип сорый инспектор блондинкадан.

– Мин аны кайдан сүндерергә икәнен белмим.

– Менә ул, рульдә, – инспектор аңлатырга дип тәрәзәдән башын тыккач, поворотник тоткасына элеп куелган сумканы күрә. – Ә бу нишләп монда?

– Ә мин аны сумка элгеч дип уйлаган идем...

10	20	30	40	50	60	70	80	90	100	110	120
1,2	3,7	7,5	13	19	27	36	46	58	71	85	101
1,5	5	10	18	27	39	67	81	89	104	125	148

«КамАЗ» — бишенче

«Дакар-2013» ралли-марафонының беренче этабында Э.Николаев җитәкләгән экипаж бишенче урынны алды. Йөк машиналары классында «КамАЗ-Мастер» командасының җиңүе инде традициягә әйләнде. Яңа меньеллыкта «КамАЗ» узышчылары 11 раллиның сигезендә җиңүгә ирешкән иде. Узган ел Чаллы дружинасы уңышсыз чыгыш ясагач, быел экипаждан җанатарлар бары тик җиңү генә көтә. Дөрес, быелгы рейдка команда сизелерлек яңартылды, стартка чыкканчы ук әлеге узышларның җиңел булмаячагы билгеле иде. «КамАЗ»чыларның әле тагын 13 этап узасы бар.

Сәхифәне
Фәнис МОТЫЙГУЛЛИН
әзерләде

ЮКСЫНАБЫЗ СИНЕ

Артист дигән җаваплы исемгә тап төшермәде

2012 ел безнең театрыбызга бик тә зур кайгылар китерде. Көтмәгәндәуйламаганда директорыбыз Шамил Закиров, талантлы артистыбыз Фирдәвес Әхтәмова, халкыбызның яраткан артисты Шәүкәт ага Биктимеров, бөек драматургыбыз Туфан Миңнуллин арабыздан китеп бардылар. Шулар артыннан Әнвәр ага Гобәйдуллиныбыз да вафат булды.



Ринат ТАҖЕТДИНОВ,
Россиянең һәм Татарстанның халык артисты

Туфан Миңнуллин үзенең бер мәкаләсендә болай дип язган иде. «Бу мәкаләне язганда, җөмләләремне тыйнаграк итеп төзергә тырышам. Чөнки Әнвәр абый – үзе тыйнак табигатьле, шапырынганны өнәп бетерми торган артист. Театр сәнгатенә хезмәт итеп, гомеренең бик күп елын сәхнәгә бәйләгән һәм бервакытта да артист дигән җаваплы, олы исемгә тап төшермәгән кеше». Туфанның бу бик тә дөрес сүзләренә өстәп, шуны әйтәсем килә: Әнвәр абый тормышта да олы җанлы, саф күңелле кеше иде.

Әнвәр абый 1922 елның 18 октябрендә Казан шәһәрендә туа. Мәктәптә укыган вакытында ук, театрга еш йөри һәм шул елларда ук аның күңеленә артист булу теләге кереп оялый. Әмма сугыш башлану аның бу теләкләрен чәлпәрәмә китерә. Ул, фрезеровщик хезмәтен үзләштереп, 1940 елдан 1946 елга кадәр Казан авиация заводында эшли. «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында фидакарь хезмәте өчен» дигән медаль белән бүләкләнә. Әнвәр абый үзенең автобиографиясендә бу авыр еллар турында бер-ике җөмлә белән генә яза. Ә яшь малай өчен бу хезмәтнең бик тә авыр булуы, шәһәрнең бер башыннан икенче башына җәяү йөрүләре турында бер сүз дә әйтми. Билгеле инде, бу зур чынығу мәктәбе була, хезмәт сөяргә, дисциплинага өйрәтә. Шушы авыр елларда да театрга булган мәхәббәте кимеми, сугыш тәмамлангач, ул 1946 елда, Татар дәүләт академия театры каршындагы театр студиясенә укырга керә. Аның беренче укытучылары зур сәхнә осталары Хөсәен ага Уразиков белән Нәҗип Гайнуллин була. 1948 елны студияне уңышлы тәмамлагач, Әнвәр абый Татар дәүләт академия театрына эшкә алына. Әнвәр абый ул вакытта ижатлары чәчәк аткан Зәйни Солтанов, Хәлил Әбҗәлилов, Хөсәен Уразиков, Гөлсем Болгарская, Гөлсем Камская, Фуат Халитов һәм Габдулла Шамуков кебек зур сәхнә осталары арасына килеп керә. Аларның ижатларына хәйран калып, нык-лап торып сәхнә серләренә өйрәнә башлый. Бик күп театр белгечләре Әнвәр Гобәйдуллинны эпизодик рольләрне оста башкара дип язалар һәм бу дөрес тә. Чөнки эпизодик рольне тамашачы күңелендә истә калырлык итеп уйнар өчен, зур башкару осталыгы таләп ителә, артисттан зур фантазия сорала.

> ***Әнвәр абый театр сәнгатенә хезмәт итеп, гомеренең бик күп елын сәхнәгә бәйләгән һәм бервакытта да артист дигән җаваплы, олы исемгә тап төшермәгән кеше»***

Эпизодик рольләр артистның осталыгын чарлый, дип юкка гына әйтмиләр. Хәзер мин Әнвәр абыйның сәхнә осталыгын чарлаган, аны сәнгать остасы дәрәҗәсенә китереп җиткергән рольләренең кайберләренә тукталып үтәсем килә. Менә бик кызыклы бер эпизод. Әнвәр абыйның сәхнәдәге беренче роле Шәриф Камалның «Козгыннар оясында» әсәрендәге Таҗи мулла. Монда ул Зәйни ага Солтановның дублеры була. Күз алдына китерегез, бу аңа нинди зур җаваплылык өсти. Әнвәр абыйның әйтеп калдыруына караганда, театрның гаҗәеп көчле артисты, театрның корифее булган Зәйни ага Солтанов аңа зур ярдәм итә һәм ул бу рольне Әнвәр абыйның үзенә генә калдыра. «Син бу рольне нәкъ мин уйнаганча ижат иткәнсең, үзең генә уйна инде, әлеге рольне сиңа тапшырам. Сине ижатыңдагы беренче уңышың белән котлыйм», – ди.

Менә шуннан Әнвәр абыйның зур ижат хезмәте башлана. Әнвәр абый театрда күп еллар эшләү чорында төрле пландагы, төрле характердагы, төрле чордагы бер-берсенә охшамаган йөзләрчә образлар ижат итте. Үзем язам, үземнең күз алдымнан Әнвәр абый тудырган образлар үтеп-үтеп китәләр. Бәхетемә күрә, мин аларның барысын да күрдем, бик күпләрендә аның партнеры булып уйнарга туры килде.

Аның ижаты матбугатта да бик зур бәя алган. Ш.Камалның «Акчарлаклар» повесте буенча эшләнгән драмадагы Шәрәфи карт образы турында берничә сүз әйтми мөмкин түгел. «Әнвәр башкаруында ул – халык күңеле байлыгын җыйган шигъри образ. Шәрәфи карт тулы канлы, тирән сулышлы кеше булып гәүдәләнә һәм тамашачылар мәхәббәтен яулап ала. Бу аның талантлы, киң колач белән ачылган гаять дәрәҗәдә табигый һәм олы образ», – дип язган Зәйни Шаһиморатов.

Чынлап та, мин моның белән тулысынча килешәм. Бик авыр чакларда да кешелеген саклап калган, һәрвакыт башкаларга ярдәм кулын сузарга әзер булган җылы, якты образ тудырды Әнвәр абый.

Режиссерларыбыз Марсель Сәлимҗанов та, Празат Исәнбәт тә Әнвәр абыйны бик яраталар иде. Шуңа күрә, аның рольсез утырганы булмады.

Әнвәр абый үзенең дусларын сыйларга бик ярата иде. Гастрольгә килеп төшкән көнне, кунакханәгә урнашуга, бәләкәй генә өстәл әзерләп, яраткан дусларын кунакка чакыра. Бөтен әйберне пөхтә итеп әзерли, яратып сыйлый.

Гастрольләрдә миңа еш кына Әнвәр абый белән бер бүлмәдә торырга туры килде һәм миңа аның белән торуы рәхәт иде. Ул иртүк торып чәй әзерли. Яшьрәк вакытта бит йокларга яратасың. Ул алдан тора, азрак тәннәрен яздыра, тавышы белән эшләп ала. Аннан төшке аш ашарга бергәләп барабыз. Без кайвакыт Әнвәр абыйның ашавы турында кызык итеп тә сөйли, ә ул көлә генә иде. Әнвәр абый ризыкны бер ягы белән 30 тапкыр чәйни, икенче ягы белән дә шулай ук. Менә шундый тәртипле, бөтен эшне җиренә җиткереп эшли торган кеше иде Әнвәр абыебыз.

Без аны бик еш искә алабыз, алар хатыны Сания ханым белән бик тату яшәделәр, күпләргә үрнәк гаилә булдылар. Аларның тормышлары җиңел булмады, кечкенә эш хакы, фатир юклык. Шундый нәрсәләр дә аларны бөгә алмады, шулай ук бердәнбер балаларының (улларының) фаҗигале рәвештә үлеме дә...

Хәзер Әнвәр абыйга 90 яшь булыр иде, бу бәйрәмен ул үткәреп өлгерә алмады, арабыздан китеп барды. Әмма, Әнвәр абый, без – сине белгән, синең белән бергә эшләгән дусларың – сине беркайчан да онытмабыз. Безнең белән бергә сине яшь артистларыбыз да соңгы юлга озаттылар, димәк, тормыш дәвам итә...

Син җитмисең, Хәлил абый!

Халидә ФӘРДИЕВА,
Татарстанның атказанган укытучысы, Казан шәһәренең 4 нче гимназиясе

Быелгы уку елында гимназиябез ничектер боегып, бушап калгандай булды. Күңелләребезне Хәлил абыебыз Мәхмүтовның юклыгы моңсуландыра шул. Сагынабыз, Хәлил абый сине, бик сагынабыз. Көн дәвамында ачык чырай белән килеп керерсең дә, кемнең кем булуына карамастан, барыбызның да хәлен белеп, ике кулың белән дә күрешеп, кәефләребезне күтәрерсең кебек тоела. Ә үзең беркайчан да зарланмый идең.

– Хәлил абый, үзеңнең хәлләрең ничек? – дип соравыбызга:

– Алда – гөл, артта – чәчәк, – дип җавап бирә идең.

Аннан синең тирәңә театрга гашыйк укучылар җыйнала, син һәрберсенең укуы турында сорашасың, аларга аталарча киңәшләреңне бирәсең, укытучыларны хөрмәт итәргә кирәклегенә басым ясыйсың һәм җайлап кына репетицияләр башлана. Башта алар узган дәресләрдә син өйрәткәннәрне сәхнәдә кабатлыйлар. Бер сүз дә эндәшми генә карап торасың да аннан кай җирләре килешеп бетмәгәнен әйтәсең. Шуннан китәсең кызып: башта куртка салына, аннан пиджәк... Репетиция кызганнан-кыза бара, күлмәкләр манма суга бата. Балалар да «ардык» димиләр, һәрбер хәрәкәтеңне, һәр әйткән сүзеңне җиренә җиткереп үтәргә тырышалар, бик дәртләнеп уйныйлар, хәтта шул дәрәҗәгә җитә ки: алар бер-берсенә нәкъ Сезнеңчә кисәтүләр ясый башлыйлар. Хәлил абыебыз канәгать: мыек астыннан гына елмаеп куя. Шушы чор эчендә кайсы гына классикларның әсәрләре куелмагандыр да, кайсы гына язучыларның юбилейлары үткәрелмәгәндер, Сезнең ярдәм белән нинди генә чаралар уздырылмагандыр! Галиәсгар Камалның «Банкрот» һәм «Беренче театр»ы, Кәрим Тинчуринның «Американ» һәм «Сүнгән йолдызлар»ы, Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»е... аларны санасаң, бихисап...

Гимназиядә уздырылган бер генә чара да Хәлил абыйсыз үтмәде. Чара уздырылган көнне Хәлил абый, бөтен эшен ташлап, гимназиягә килә һәм үз «артист»ларының ничек уйнауларын арттан бик җентекләп күзәтә. Аларның чыгышыннан соң балаларны җыеп, укучыларның сәхнәдә ничек уйнауларына анализ ясый, мактау сүзләре әйтә. Әлбәттә, бу вакытта балаларның күзләрендә очкыннар кабына, ә аннан илһам белән аларның житешсез якларын күрсәтә, репетицияләр вакытында әлеге төгәлсезлекләр кабат-кабат эшкәртелә.

Укучылар белән генә түгел, хәтта укытучылар белән дә спектакль куйганыбыз хәтердән чыкмый. Туфан Миңнуллинның «Үзебез сайлаган язмыш» әсәрен сезнең җитәкчелектә ничек шәп итеп әзерләгән идек. Укучылар һәм укытучылар белән әледән-әле уздырылган конкурсларның берсе дә Хәлил абыйның катнашыннан башка үтмәде һәм аларның барысының да нәтиҗәсе уңышлы булды.

Хәлил Зәки улы искиткеч кешелекле, ярдәмчел иде. Бервакыт (җәй айлары) мәктәп психологының (ул Актаныш районыннан) үз туган ягына кайтканда Алабуга шәһәре янында юл һәлакәтенә очравын мәктәп директоры Ирек Әһли улына хәбәр итәләр. Директор бу кыз бала янына ничек барып хәлен белергә икән дип аптырап торганда, мәктәпкә Хәлил абый килеп керә һәм: «Машинаны рәтлим дә бергәләп Алабуга хастаханәсенә барып кайтырбыз», – ди. Шул көнне үк ул китапханәче Фирдәвес Фәрит кызы һәм рәсем укытучысы Зөлфия Габделхәй кызы белән бәлагә юлыккан кыз баланың хәлен белешеп тә кайта. Әйе, Хәлил абый зур хәрефтән Кеше иде шул!

Хәлил абый Мәхмүтов талантлы артист кына түгел, ул әле чын мәгънәсендә педагог та, режиссер да булды. Ул безнең гимназиядә (элекке 73 нче мәктәп) 1994 елдан бирле эшләде. Хәлил абый балаларыбызга матур сөйләм дәресләре бирде һәм, театр түгәрәге алып барып, бик күп балаларны сәнгать юлына этәрде.

Синең игелекле хезмәтең беркайчан да күңелләрдән чыкмас, Хәлил абый. Син биргән акыллы киңәшләр һәрчак йөрәкләребездә сакланып, балаларга белем һәм тәрбия бирүдә ярдәм итеп торырлар.

КАЛӘМЛЕ ГАЛӘМ

Зыялы кеше – зыянлы кеше?

Бибәл Норел

ҖАВАП

(Бер хатирә)

Узган гасырның сиксәненче елларында булса кирәк (аен-көнен дә төгәл хәтерләмим инде), «Татарстан яшьләре» газетасы редакциясе каршында эшләп килүче Яшь иҗатчылар берләшмәсенең чираттагы утырышына ике күренекле әдип – шагыйрь Нури ага Арсланов белән прозаик Барлас абый Камалов килде. Очрашу вакытында алар, чыгышларын аралаштырып, берләшмә әгъзаларын кызыксындырган сорауларга тәфсилле җавап бирделәр. Нури ага исә, соңгы араларда язган кайбер шигырьләрен, шул исәптән, безнең үтенечне дә искә алып, 1969 елда ук язган үтә кыю «Атлантида»сын укыды. Шигырьләр (аеруча – «Атлантида», гәрчә күпләребез аның белән инде таныш булсак та) гаҗәеп көчле тәэсир итте.

Ләбиб ЛЕРОН

Алкышлар тынуга, арабыздан кемдер, әлеге әсәрләр йогынтысыннан айный алмыйча, ахры, олпат әдипкә шундыйрак рухтагы соравын җиткерде:

– Нури ага, утыз җиденче еллар гарасатыннан ничек исән калдыгыз?

Шул вакытта мин аксакалыбызның җавабын сары битле кәгазьләргә теркәп куйган булганмын. Җавап язылган ике бите бар, ләкин, ни кызганыч, датасы күрсәтелгән баш өлеше каядыр юкка чыккан – күпме генә эзләсәм дә, таба алмадым. Шулай да җавапның булган кадәресен, Нури ага бәян иткәнчә, укучылар игътибарына ирештерергә булдым:

– ...шуннан гәзиттә минем турыда берәүнең мәкаләсе басылып чыкты. Эт иткән инде. Ничек каралтып була – шулай каралткан... Кызлар белән йөри, дигән хәтта. Соң, кызлар белән йөрмичә, тагын кем белән йөрим инде, атаң башы... (*Дәррәү көлеш.*) Ул вакытта мин «Яшь ленинчы» белән «Пионер каләме»ндә рәссам булып эшли идем (*1912 елның 12 сентябрендә Казакъстанның Петропавел каласында эшче-көнлекче гаиләсендә туган Нури ага, 1928 елда Күкчәтау җидееллык татар мәктәбен тәмамлагач, Казанга килеп, 1928-1931 елларда сәнгать техникумында белем ала.* – **Л. Л.**). Татарстан китап нәшрияты белән дә хезмәттәшлек итәм. Белеп-сизеп торам – минем баш очында да болытлар куерып маташа. Ике-өч көн элек кенә бүлмәдәшем, дустым, якташым Ибраһимны (*И.Салахов (1911-1998)та Казакъстанның Күкчәтау шәһәрендә туган.* – **Л. Л.**), төнлә килеп, алып киттеләр. Кая да булса еракка китеп кенә бу афәттән котылып калу мөмкин икәнлеген аңлап, тиз генә җыендым да, башта Чимкент, аннары Алма-Ата тарафына юл тоттым. Ярый әле, китәр алдыннан, хезмәтемә тиешле әҗеремне алган идем, ул акча миңа ярты елга җитте. Көн үткәреп ятам шулай. Эзләүче-нитүче, минем белән кызыксынучы кеше юк. Шуннан кабат Казанга кайтырга булдым. Кайтуга, рәссам-бизәүче булып, филармониягә эшкә урнаштым. Үзем тегеннән килеп алганнарын көтеп йөрим. Көннәрдән беркөнне, күпме качып йөрергә була инде, дип уйлап, киттем тимер юл милициясе пунктына (НКВД шунда урнашкан иде).

Фото Л.ЛЕРОН архивыннан алынды

Кыяфәте белән татарга охшаган начальник, мине күрүгә:

– Нәрсә кирәк? Ни булды? – дип сорады.

– Бөтен дусларны алып бетердегез... Аларның бер гаепсез икәнен үзегез дә беләсез. Иректә татар язучылары, татар журналистлары калмады... Мине дә хәзер үк алыгыз! – дидем.

Теге, бер сүз дәшминитми генә алдындагы кәгазьгә нидер язгач, сакчысын чакыртып кертте дә:

– Машина шунда тора. Моны илт! – диде. Аннары миңа карады: – Йоклагыз. Иртәгә чыгарып җибәрерләр...

Шулай итеп, мине айныткычта төн кундырып чыгардылар. Бераздан совет-фин сугышына киттем. Анда да үземчә хаклык эзләп йөрим. Тыныч тормышта юк икән, ичмасам, сугышта бардыр әле, дим. Чынлап та бар икән ул анда. Пуля килеп тисә, аңа генерал ни, солдат ни, барыбер – икесе дә үлә... Шулай тигезли...

Шигъри хәтер

Нури АРСЛАНОВ
(1912-1991)

АТЛАНТИДА

Атлантида булды микән чынлап?
Тынгы бирми сорау һич кенә:
Әллә кайдан, ерак-ераклардан
Һәлакәтле бер моң иштелә.

Кинәт юкка чыккан бөтен кыйтга,
Тау дулкыннар күккә ашканнар:
Бер мизгелдә илләр, шәһәрләрне,
Һәйкәлләрне сулар басканнар.

Океан убкан кебек Атлант җирен,
Дәүләтләрне монда җир убкан:
Дәште-Кыпчак, Болгар, Алтын Урда...
Бер-берсенең тамрын корыткан.

Ничә тапкыр килгән монда яулар,
Кичергәннәр илне кылычтан...
Калдыгын да көлгә дүндерергә
Миссионерлар күпме тырышкан.

Сәхифәләр тузган, юкка чыккан...
Ә без – менә, без – бар, булганбыз!
Фал ачабыз ләкин, баш ватабыз:
Әллә кыпчак, әллә болгарбыз?

Кем булгандыр бабам? Кыпчакмы ул,
Болгармы ул? Нинди аерма?!
Татар дигән исем йөртәбез без –
Татар каны ага тамырда!

Атлантида! Атлантида баткан!
Эз калмаган бөек халыктан...
Ә без – менә, без – бар, эз бар җирдә –
Без батырган саен калыккан.

Атлантида язмышы юк безгә,
Оныкларның ачык бабасы:
– Нәселең кем? – дип сорасалар әгәр,
Әйтерләр:
– Без – татар баласы!

Татарстан дигән ватаным бар,
Татар дигән халкым бар минем.
Узганнардан түгел, мин халкыма
Киләчәктән урын барлыймын.

1969

Хикмәтле шигырьләр

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ

Һәркемдә үзенеке

Греклар яд итә микән
Платон төрбәсен?
Безнең истән
чыкмый гел дә
Пләтән төрмәсе...

Эшең белән дәлиллә

Бәйрәмнәрдә
«Әпипә»гә
Йөрсәң дә биеп кенә,
Татар булып булмый,
туган,
Түбәтәй киеп кенә.

Геройлар без

Җүләрләнми ничек
яшәлгәндер?
Шул сорауны бирәм
бүген дә.
Акыл җуймау –
бик зур батырлык ул,
Рәсәй дигән
сәер бу илдә...

Сатылмый торган һөнәр

Зур дәрәҗә
яулап алу мөмкин
Таныш-белеш, дуслар,
«брат» белән.
Һич сатылмый торган
бер һөнәр бар:
Шагыйрь булып
булмый блат белән!

Демократиянең ике төре

Америка
үрнәк күрсәтте шул,
Сайлап куеп
бер негр малаен.
Ә Рәсәйдә татар
илбаш булу
Төшемә дә кермәс,
мөгаен...

МИН ДӘ ЯЗДЫМ КӨНДӘЛЕК

(Әдәби фонд директоры язмалары)

30 сентябрь, 1987 ел

Рус шагыйре Николай Беляевны 50 яше белән котладык. Шактый еллар Казанда яшәп иҗат итә. Чын урыс шагыйре нинди булырга тиешлекнең – үрнәге ул! Шигырьләре – кызык, үзенчәлекле. Сүз уңаеннан, миңа урысча иҗат иткән үзебезнең Рөстәм Кутуй, «читтән» – Николай Рубцов, Леонид Мартынов (Такташның байтак шигырен русчага «аударган» шәхес), Юрий Кузнецов иҗаты күбрәк ошый.

* * *

Язучылар йортында күренеп киттеләр: И. Юзеев, Н. Беляев, Р. Мингалим, Р. Хәмид, Г. Морат, Р. Кутуй, М.Галиев, Р. Зәйдулла, Ә. Мушинский, Ә.Гаффар...

* * *

Хатыным Фидания белән кич Зөлфәт абыйлар фатирына (Татарстан урамы) бардык. Зөлфәт абый Киндерледән дача өчен җир кишәрлеге алып йөри икән. Сәгать сигезләрдә генә арып-талып кайтып керде.

Көн кадагы

Татарстан Дәүләт Советының Президиум әгъзасы, Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев ошбу елның гыйнвар башларында Бәкер санаториенда дәваланып кайтты.

* * *

Республиканың М.Җәлил исемендәге премиясе лауреаты, шагыйрь Газинур Морат, «кышкы каникул» көннәрендә чаңгыда шуып һәм даими мунчада булып, җанын-тәнен сихәтләндереп ләззәтләнде.

* * *

Яшь шагыйрь Рүзәл Мөхәммәтшин күптән түгел генә Мөслим төбәгендә – хатынының туган авылы Әмәкәйдә (язучы Факил Сафин белән галимә Дания Заһидуллина да шушы авылдан) бер атна чамасы кунак булып, шушы якның табигате белән хозурланып, илһамланып, язарына рухи тәгам җыеп кайтты.

* * *

Шушы елның 17 гыйнварында 17. 00 сәгатьтә Язучылар йортында (Мөштәри урамы, 14) танылган язучы Альберт Хәсәновның иҗат кичәсе була. Рәхим итегез!

Туган көннәрен гел истә тотыйк,
Барчасын да, әйдә, бергә котлыйк!

15 (1946) – **Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ,** шагыйрь.

15 (1958) – **Вазыйх ФАТЫЙХОВ,** шагыйрь.

Фәрит МУЛЛАХМӘТ рәсеме

Хатының Муза да булса...

Сәхифәне Ләбиб ЛЕРОН әзерләде

ЮБИЛЕЙ ИЛӘ

Алтыдагы — алтмышка

Остазың турында фикер әйтүдән дә кыенрак нәрсә юк икән. Сиңа канат ныгытырга булышкан, беренче очышыңны үзе тын да алмый көч биреп карап торган, һәр уңышыңны, һәр кимчелегеңне үзенеке итеп кабул итүче шәхес турында авыз тутырып бәя бирү җиңел эшме әллә?! Илфак Ибраһимов – шагыйрь Мөхәммәт Мирза да минем өчен шундый остаз. Җитәкләп әдәбият дөньясына алып кергән кеше дә.

Әле дә хәтерлим, Актаныштa эшләп килүче «Агыйдел дулкыннары» иҗат берләшмәсенә йөри башлаган еллар. Мин – мәктәп баласы, әнигә ияреп, шигырь тыңларга төштем. Үземнең куен кесәсендә дә бер шигырь ята. Укырга кушкач, укып бирдем моны. Ул вакытта яшьләр белән эшләүче Әмирҗан Моталлапов, Хәмит абый Миңнегалиев, Илфак абый, энә күзеннән үткәреп, шигырь тыңлый. Тыңлап бетерүгә исә, Илфак абый: «Ә теге егеткә багышланган мәхәббәт шигырен ник алып төшмәдең?» – димәсенме! Берләшмә җитәкчесе каян белгән, дип, минем биткә кызыллык йөгерә. Болай гына, котыртып кына сорыйдыр, дип, башка да килми бит, әй... Икенче юлы борынлый гына башлаган мәхәббәт шигырьләре дә авылдан район үзәгенә минем белән «иярә» төшә. Аннан Илфак абый Казан шагыйрьләре белән таныштыра, беренче китабым белән котлауга ук: «Синең инде икенче китаплык куәсең бар, Харрас абыең Әюп синең иҗатың белән кызыксына, аның хәер-фатихасында ниятлә», – ди...

Хәзер дә шаккатып утырам – кемгә генә тәти икән шундый җитәкләп баручы остазлар, кем үз вакыты бәрабәренә кеше шигырьләрен тәмләп укырга, иҗатын сипләп утырырга күз нурын кызганмый?! Илфак абый ул нисбәттән бик күп яшьләрдән рәхмәт сүзе ишеткән шәхес. Татарстан Язучылар берлеген җитәкләгән елларда гына да яшьләр өчен эшләгән хезмәте бихисап булды. Остаз була белү генә түгел, иҗатта яшьтәш тә булып кала белә ул. Яңадан-яңа китапларын бүләк итүдән бигрәк, синең әлеге китабы турында фикереңне кадерлерәк аңа.

60 яшьлек юбилее алдыннан да Илфак абый белән озаклап гәпләшеп утырырга җай чыкты безгә. Газетабызга шигъри шәлкемен бирер алдыннан да мин аңа: «Бүгенге зирәк, акыл туплаган шигъриятегезгә караганда, миңа Сезнең башлангыч иҗатыгыз, ярсу, гади-самими хисләрегез күбрәк ошый», – диюемне дә елмаеп, рәхмәтле булып кабул итте ул. Шуңа өстәп, үзең сайлап ал, үзең шәрехлә, диюенә генә каушап төштем. Минме?!.

Әмма мин аның робагыйларын сайлап алырга булдым. Мөхәммәт Мирзаның мәхәббәт лирикасы рухи халәтемә күбрәк якын булса да, яшьлек каланчам аркасында, шагыйрьнең бүгенге йөзен, бүгенге халәтен бик артында калдырудан курыктым. Ә аның шигырьләре шагыйрь күңеле кебек үк үз эченә зур галәм сыйдырган.

Туган көнегез белән, Илфак абый! 60 яшьлек юбилеегыз уңаеннан Сезнең укучыларыгыз, «Шәһри Казан» газетасы редакциясе, күпләгән шәкертләрегез исеменнән ихлас котлау кабул итегез. Сәламәтлек, күңел көрлеге, иҗат киңлеге телибез Сезгә! Алтыдагы алтмышка булсын да, күңелегез Актаныш Нөркәләре арасында адашып калган яшьлек иленнән китмәсен.

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА

Мөхәммәт МИРЗА

Робагыйлар

* * *

Үткәненә кире кайтканнар да бар,
Кайтып җитми кире кайтканнар да бар...
Кайтып җитеп үзен таный алмыйча
Үз-үзеннән күңле кайтканнар да бар...

* * *

Маңгаема бәрелде дә таң җиле,
Сәламеңне алып килдем, ал, диде...
Ятагыңның исе йөзгә ягылды,
Миннән бәхетле тагын кем бар инде...

* * *

Әлегәчә ни булганын төшенмим:
Өн идеме, әллә инде төшемме.
Белештерми үкси-үкси еладың
Бер күтәреп, бер төшереп түшеңне...

* * *

Бердәнбереңбулырмын, дигән идең,
Гомереңә тулармын, дигән идең...
Тәкъдиренә язылганын кем белә,
Булдың тик тәүге кырау тигән гөлем.

* * *

Тәненә госел – су алып коенганы,
Җанына госел – сәҗдәдә оеганы.
Хатадан хали – тыйганнан тыелганы,
Бер гөнаһсызы – иманга сыенганы...

* * *

Барып җитәрсең сукмакның такырыннан
Урау булса да хәтта күп чакрымнар.
Өлешең алтын да, өлешең көмештер...
Йөз чөймә бирсәләр җизеннән,
бакырыннан.

* * *

Җиңелгәннең дәгъвасы һич бетәсе юк,
Кайчандыр бирерләр дип көтәсе юк,
Язылмаган кануннары күп дөньяның,
Бер төшкәнне күтәрәм дип этәсе юк.

* * *

Хәтта филне күтәрдем дип сөйләп була,
Күтәрмәсәң, сөйрәдем дип сөйләп була.
Телнең сөяге булмаган һәм булмас та,
Ачык авызны һәркайда сөяп була...

* * *

Хәлең ничек, дисәң, хәл бер көенчә,
Ипекәй бар, гаилә сөтле чәй эчә...
Тик җирләрне менә бүлеп алдылар,
– Алабыз, дип, алдан бер сүз әйтмичә.

* * *

Кагыйдәсез уеннарны күп кордың...
Күзгә карап, кулларга куз тоттырдың...
Уйный-уйный бар көндәшеңне
кырдың...
Бердәнбер калдың – барыбер
оттырдың...

* * *

Шөкер, кемнәрдәндер алып бүләсе юк,
Шөкер, кемнән булса алып түлисе юк...
Шөкер, гомер көзләремдә тезем төшеп,
Ходайдан ары һичкемгә түнәсе юк...

* * *

Беләм, бердәнбереңтүгеллегемне,
Белә-белгәннән җан күпме теленде...
Беләм: мин бердәнбер сугаручыңмын
Сусап сулыккан күңелең гөлеңне...

* * *

Бар гавәм күрде гыйбрәтле өч мәлеңне:
– Үз арбаңнан чит арбага күчкәнеңне;
– Ятка: «Мәңге бергә», дип, ант
эчкәнеңне;
– Арбаларыңнан мәтәлләп төшкәнеңне...

* * *

Алыш-биреш асылында замана,
Бармаклар ничә бөгелеп санала...
Үз исәбең үзең белән булсын гел...
Алганда ни биререңне чамала...

* * *

Дөньясы базар – мыскалда бар малы,
Мал эзләп җирнең читенә бармалы.
Үзен-үзе белә-белгәннән алып,
Исәп-хисапта бәндәнең бармагы...

* * *

Әле бабаң түбә астында торасың,
«Дөнья безнеке мәңге!» – дип лаф
орасың...
Белеп тор син, куласаның бер басарын,
Соратып ал соңармый тәүбә догасын.

* * *

Хәбәрләр синең хакта җитәрлек.
Ишетүгә барсын хушсыз итәрлек...
Утсыз төтен чыкмасы анык мәгълүм:
Бөтен ыруың сөргенгә китәрлек...

* * *

Үзеңә дә шул көн килер, чамала,
Берьялгызың калырсың шыр далада.
Бөтенлектән бөлгенлеккә бер карыш,
Хәлең белмәс хәтта ала карга да...

* * *

Мәгълүм: һәркем бу дөньяда
кунак кына...
Мәгъкүмдер гомер сөрүләр тыйнак
кына...
Мал-мөлкәте, сый-хөрмәте төрлечә тик:
Мәхлукның йорт-кабере дә җыйнак
кына...

* * *

Әйбәт егет булып телгә кергәнсең,
Нинди сөягең сөйкемле, белмәссең...
Юкса гомерең буе дус-иш, кардәшне
Син кәкре каенга терәп йөргәнсең.

* * *

Хуш: алтыдан алтмышына да җитте,
Атасы малы башына да җитте...
Хуш: авылдашлар ташламый бер-берсен,
Картлар йортына машинада китте...

* * *

Дога йорты кордыргансың – ниятең зур,
Бабаң кырдырган иде – җинаяте зур...
– Ярлыкагыл, бер Ходам, – дип,
тәүбә ит, син,
Һимаяче, шигъремнең кинаясе зур...

* * *

Эссе, бөркү – күрәм ничек ашыккансың,
Чиләгең алып коебызга чыккансың...
Үзе туйган, күзе туймас карт
мәҗнүнмен,
Япма, зинһар, изүләрең ачык калсын...

* * *

Дөнья базар: сатыйк, сатып алаек,
Гамәлендә тиң аркадаш табаек.
Дус-туганнан йөз чөермик, шулай да
Ни чәчкәнен, ни урганын караек...

* * *

Бүре орынмас ятлар калдыгына...
Тәгаме – җылы тән һәм каны гына...
Баксаң, бер аермасы юк бәндәдән,
Бар «явыз» дип тагылган даны гына.

* * *

Дәүләтсез дә ил булала, уйласаң,
Милләт дигән минлегеңне җуймасаң...
Хак кыйблага карап тоткан юлыңда
Иман хилафлыгыңа юл куймасаң...

* * *

Шөкер, тук халык – бәрәңгесен кабып;
Шөкер – бары белән өс-башы ябык...
Патшалар кабат сугыш башламаса,
Шөкер итмәслек сәбәп булмас табып...

* * *

Хәбәрдәрсең һәр колыңның гамәленнән,
Хәләл яки хәрам җыйган тәгаменнән...
Рәхмәтең киң, ярлыкарсың күпләрен дә,
Шөкер! сүзен ишетерсең
ни кадәреннән?!.

* * *

Кемнәргәдер юраганы юш килә,
Юш килгән бере күңелгә хуш килә...
Кемгәдер кыйммәт, кемгәдер буш килә,
Килгән-киткәннән күңелгә уш килә...

* * *

Атың барда атланырсың, җигәрсең...
Атың барып җиткән җирләр гизәрсең...
Атсыз дигән яманатың чыкса бер,
Бар тапкан-ирешкәнеңнән бизәрсең.

* * *

Татар башын саныйлар ди тагы да,
Өлкән туган батты кара кайгыга:
Баш санын булыр кечрәйтеп, тарайтып
Җанын ничек иманыннан айырырга?

* * *

Аһ, сөймиләр берсен-берсе, аһ,
сөймиләр,
Ул тегеләй, ул болай, дип сөйлиләр.
Ә чынында әләкче ул гайбәтчеләр,
Имәннәрне бит юкә белән чөйлиләр.

* * *

Әле куеныма алып җылыталам.
Әле үзем дә куеннан җылы табам...
Шул рәхәтнең газабыннан аермасын...
Әле көнләп, көнләштереп яраталам...

* * *

Әдәплекнең шома битлеген каплап,
Төп-төз басып йөрисең кыек атлап...
Дөнья чүбен чөям дисең күтәреп,
Чәнечкеңә сәнәк саплыгын саплап...

* * *

Күп белдекләләр күп булган элек тә...
Үзгә фикерне тормаган элеп тә...
Барсын бергә җыйсаң да тиң булалмас:
Син – бөекләр бөеге мин-минлектә...

* * *

Фәрештә түгелсең, читкә йөргәләдең.
Кояш батуга, уҗымга кергәләдең.
Кардәш-дусның маңгаена мөгез куеп,
Күрәләтә: «Син – мүкләк»,
– дип сөзгәләдең...

* * *

Уяу тор бу дөньяның һәр очрагына,
Җил-давылы йомычкадай очыра гына.
Күкләр өчен Адәм гомре – Аһ! дигәнче
Дөрләп янып, сызып сүнәр чыра гына...

* * *

Туган җирең – кендегең төйнәлгән төш,
Яшимен, дип, дөньяга инәлгән төш.
Бары-югына багып кинәнгән төш,
Гомереңне үткәреп җибәргән төш.

* * *

Шундый-шундый хәлләр бездә:
тыңлале,
Тыңлаган булып тыңламый тормале.
Күкләргә кемдер күтәрмәк безләрне,
Койрыгыннан эләктереп торнаны!

* * *

Дөнья тигезсез һәм түгел хатасыз,
Без – басуда, ә сез өйдә ятасыз...
Сезнең өчен бөгелә безнең билләр,
Ә сез кем өчен чикләвек ватасыз?!.

* * *

Сездә булган байлык бездә юк анысы,
Тапканын җиткерәсе дип көн саныйсы...
Ачның хәлен тук белмәс – күптән
мәгълүм,
Тук йөзеңә нигә мескенлек ясыйсың?

* * *

Милли ашың булса төче кыстыбый,
Сине һичкем ау чыгарга кыстамый...
Тары җирең, киндер җирең чәч тә ур...
Мир табыны тулып торсын бал да май.

* * *

Бездә генә шундый күркәм ыспайлык,
Ел тәүлеге вазифалы, без айнык...
Хак бәяне генә һаман белмиләр:
Бездәй колың булу – хисапсыз байлык!

* * *

Шагыйрьлегеңне исбатла һәр көн язып,
Көндез йоклап, йөрмә төнозыны азып,
Иблис сузган хәрам калҗага алданып,
Үз-үзеңә чыгалмаслык чокыр казып...

* * *

Каян килгән сиңа шундый сорылык,
Анаңа бүре киткәнме орынып.
Йөз, төсеңә күнегелер – ничара...
Тозсызлыгыңа юк түзеп торырлык.

* * *

Әйттеләр: йөрер, йөрер дә утырыр...
Нәфес чиләген ул да бер тутырыр...
Тәүбә итеп, гыйбадәтен дә кылыр.
Тик йөзендә калыр күңле тутыгы...

* * *

Ярыннан ташып чыкса да ярсудан,
Ярына кайтып сыена бер тынып.
Аерым яши аламы дәрьясыннан,
Дәрьясыз яр торыр бары тутыгып...

* * *

Ул бердәнбер сер саклаучы – ише бер,
Утыз ике сакчы саклый ишеген...
Ачыдан-ачы ул, татлыдан-татлы,
Ачкычын тапсаң, бар сере чишелер...

Вак-вак атлап — зур җиңүләргә

Безнең белешмә

Тулы исеме: *Алия Айдар кызы ФӘЙЗУЛЛИНА*
Туган ягы: *Лениногорск шәһәре*
Уку урыны: *КФУның идарә итү һәм территориаль үсеш институты, III курс студенты*
«Созвездие-Йолдызлык», «Студентлар язы», «ТР студентларының иң яхшы җыры», Р. Бикмуллин исемендәге фестиваль, «Ел студенты» һ.б. конкурслар лауреаты, күптөрле стипендияләр иясе. Быел Оксфорд стипендиясенә лаек булган.

ТАНЫШТЫРУ

Фәнзилә МОСТАФИНА

Күзгә кердек дигәндә генә, кинәт күк йөзе аязып китсә, әй шатлана инде күңел! Бөтен дөнья нурга-моңга күмелгәндәй була. Алия белән без шундый көзге матур көннәрнең берсендә очраштык. Кояш кебек елмаеп кына торган зәп-зәңгәр күзле, озын алтынсу-сары чәчле кыз белән рәхәтләнеп җыр-моң диңгезендә йөздек.

Бу диңгездә Алия күптәннән инде. Шуңа күрә, курыкмыйча, колач салып йөзә. Җырлау сәләте борынгы әби-бабаларыннан ук килсә дә, Алия Фәйзуллина – нәселләрендә музыкаль белем алган беренче кеше. Лениногорсктагы музыка мәктәбендә 8 ел укыган, аны кызыл диплом тәмамлаган. Җырдан башка тора алмаса да, югары белемне башка юнәлештә сайлаган. Әңгәмәбезне Алиянең җырга булган мөнәсәбәтен ачыклаудан башлап җибәрдек.

– Музыка мәктәбендә белем алырга теләвемә әйдәгеләр каршы килмәделәр. Җырга башта ук хобби итеп кенә карадым, җитдирәк һөнәр үзләштерәсем килде. Муниципаль-дәүләт хезмәткәре белгечлеге шунысы белән кызыктырды – әлеге эшне иҗат белән бергә алып барып була. Аннан соң бик дәрәҗәле һөнәр дә бит. Миндә оештыру, идарә итү сәләте дә юк түгел *(елмая)*.

– Җырга хәзер дә хобби итеп кенә карыйсыңмы?

– Юк, киләчәктә үземне җырчы буларак та күрәм.

– Син катнашкан, лауреат булган конкурслар исемлеге шактый озын. Бәйге-ярышларга ничек «чумдың»?

– Барысы да шул музыка мәктәбендә укыганда башланды. Алтынчы сыйныфта хор укытучым күреп алып, «Созвездие-Йолдызлык» фестивалендә катнашып карарга тәкъдим итте. Анда 18 яшемә кадәр катнаштым. Аннан күреп, башка бәйгеләргә дә чакыра башладылар. Җиңүләр җиңел бирелмәде миңа. Һәр елны берәр адым гына алга атлый идем. 2007 елда, ниһаять, «Созвездие-Йолдызлык»та үзем язган «Ятим бала» җыры белән беренче урынга лаек булдым.

– Димәк, үз җырың җиңү китергән инде. Комбайн турында, ура, суга, җилгәрә, үзе тәэп җибәрә, диләр. Болай булгач, син музыкаль комбайн булып чыгасың бит?

– Чит авторларның җырларын җырларга яратмыйм шул. Әти-әнием дә моңа каршы. Халык җырлары булса гына искәрмә ясалырга мөмкин.

Җырларны 14 яшемдә яза башладым. Кемгә ничектер, миңа көй белән сүзләр бер үк вакытта килә. Онытылганчы, тизрәк язып куярга ашыгам.

– Әй җырларыңны профессиональ шагыйрь һәм композиторларга күрсәтеп караганың бармы?

– Бар. Иң беренче җырларымны композитор Риф абый Гатауллинга күрсәткән идек. «Җырларының көйләре үзенчәлекле», – дигән иде ул. Бу җирен үзгәрт, теге өлешен төзәт, дигән сүзләр ишеткәнем юк. Шулай да дөрес тәнкыйть сүзләре әйтүләрен теләр идем. Җыр сүзләрен шагыйрьләргә аерым күрсәткәнем юк. «Созвездие-Йолдызлык»та аларны барыбер Язучылар берлеге әгъзалары карый бит инде.

– Алия, сәхнә костюмнарын тектерәсеңме, әллә сатып аласыңмы?

– Безнең гаиләдә шундый шаяру да яши: әти – спонсор, әни – продюсер *(көлә)*. Беренче сәхнә күлмәгемне әле дә хәтерлим. Ап-ак күлмәкне әтием махсус «Созвездие-Йолдызлык»та чыгыш ясар өчен сатып алып биргән иде. Апаларым да күлмәкләр тегеп бирәләр. Гардеробымны ел саен бер күлмәккә булса да тулыландырырга тырышам.

– Университетта җыр-моң сөючеләр өчен мөмкинлекләр бармы соң?

– Бар, уку йортыбыз һәрвакыт иҗат дөньясында әйләнә. Музыка мәктәбендә укыганда, күбрәк русча җырларга туры килде. Татар халык җырларын башкарырга тилмерә идем инде! Һәр борылышын, ноталарын өйрәнәсем килде. КФУда татар халык хоры барлыгын белгәч, туры шунда киттем. Музыкаль белемем булса да, хәйран тырышырга туры килде миңа. 2011 елда җитәкчебез Ирнис абый Рәхмәтуллин мине солист итеп куйды. Быел хорыбызга 45 яшь тула.

– Белгечлегең, син фәнни хезмәтләр дә язасың бит әле. Киләчәк турында уйланырга, хыялланырга вакыт каламы?

– Мин укырга яратам. Мәктәптә үк төрле проектлар эшли идем, университетта да фәнни эшчәнлегемне дәвам итәм. Киләчәктә консерваториягә керергә, фән кандидаты дәрәҗәсенә күтәрелергә телим. Ел саен бер җыр яздырырга тырышам. Тавыш режиссеры: «Син университетны тәмамлаганда диск чыгарачаксың инде», – дип көлә.

КЫҢГЫР ЭШ

Тәрәзәне ватып кереп...

Буа районының Боерган авылында 30 декабрь төнендә 32 яшьлек ир-ат 73 яшьлек карчыкны көчләгән. Тәрәзәне ватып өйгә кергән ир-атка ялгыз карчык каршы тора алмаган. Хәзерге көндә җинаятьче эзләүдә.

Түләп торыр хәлем юк

Казанда 40 тапкырдан артыграк административ хокук бозган 38 яшьлек ир-ат тоткарланган. 39 мең сумнан артыгракка җыелган штрафын түләмәгән өчен, аны дүрт тәүлеккә төрмәгә утыртырга дигән карар чыгарылган. Ир-ат гаебен тулысынча таныган.

Кисәтсәгез дә, сатам

Казанда соңгы атна дәвамында полиция хезмәткәрләре алкоголь продукциясе сатыла торган 600 ноктаны тикшергән. Тәртип бозулар буенча 219 беркетмә төзелгән. Күп кенә сатучыларның төнлә сыра һәм аракы сатарга ярамаганын белә торып та бу эшкә барулары билгеле булган.

Барысын төшереп торган

Лаеш районының Нармонка авылында 12 гыйнвар көнне билгесез зат юл хәрәкәте инспекторына карата көч кулланган. Нармонка авылында ЮХИДИ хезмәткәрләре янынан зур тизлектә алгы тәрәзәләре караңгылатылган «ВАЗ-2107» узып киткән. Полиция хезмәткәрләре аның артыннан барырга булганнар. Туктарга тиешле машина тизлеген тагын да арттырган гына. Урамда басып торган егетләр төркеменә гараж ачкычын ыргытып, машина шоферы алардан гаражны ачуларын үтенгән. Гаражга кергәннән соң, машинадан коелган ир-атлар инде артларыннан килеп җиткән полиция хезмәткәрләре белән сугыша ук башлаганнар. Булган хәлләрне исә видеорегистратор теркәп төшереп барган...

Тракторлар үткәндә калды

ЯШӘЕШ

Соңгы араларда милләттәшләребез әби-бабаларыбыз кушкан исемнәргә мөрәҗәгать итә башлады. Кечкенә балалар арасында Әмир, Мәрьям, Кәрим, Мәдинә, Камилә, Мәликә, Камил һәм Әминә исемнәре бик күп. Трактор, Камаз, Лимон исемнәре хәзер, шөкер, үткәндә калды.

Ә менә андый мөгез чыгаручылар, бездә булмаса да, башка илләрдә очрап куя. Әйтик, Казахстанда яшәүче бер гаилә 1 гыйнварга каршы төндә туган балаларына Елка исемен кушкан. Мондый гадәти булмаган исемне алар Яңа ел бәйрәме символына багышлап биргән. Улының әнисе Алмагөл әйтүенчә, әлеге бәйрәм исеме сабыеның тормышын тылсымлы һәм бәхетле итәчәк. Елка – гаиләдә икенче бала. Ел ярым элек Алмагөл кыз бала тапкан. Аңа гадәти казах исемен кушканнар.

Европада исә соңгы елларда балаларына әкият геройлары исемнәрен бирү популярлашкан. Социологлар моны Уолт Дисней компаниясе һәм башка мультипликация студияләренең продукциясе популярлашу белән бәйләп карый. Көнбатышта әкият геройлары хөрмәтенә кушылган иң билгеле исемнәр булып Динь-Динь һәм балык кушаматы Немо тора икән. Дизель, Шторм, Блейд һәм Зико исемнәре дә алардан калышмый. Америкада исә балаларның туу турындагы таныклыкларына Лютик, Пайпер, Стар, Киззи, Синдерелла, Снуппи һәм хәтта Гарфилд исемнәре язылган.

Психологлар исә моны ата-аналар сабыйларының исеме белән охшаш булмасынга куя дип аңлата. Балалар һәм яшьләр яратып караган «Гарри Поттер» һәм «Сумерки» фильмнары геройлары исемен бирү дә модада кала. Эдвард, Белла һәм Гарри исемнәрен инглизләр генә түгел, башка милләт кешеләре дә бик яратып куша, имеш.

Соңгы ун елда Россиядә теркәлгән гадәти булмаган ир бала исемнәре: Дельфин, Ангел, Север, Ветер, Океан, Аладдин, Герой, Авиадиспетчер, Царь, Принц, Король. Кыз бала исемнәре: Жужа, Приватизация, Виагра, Луна, Забава, Царица, Рябина, Изумруда, Клеопатра, Тюльпан.

Питер командасы янә УНИКСның борынына чиртте

СПОРТ

Санкт-Петербургта узган ВТБның Бердәм лига чемпионатында Питерның «Спартак» командасы Казан УНИКСын 84:68 исәбе белән отты. Шулай итеп, бу уенда УНИКС «Спартак» тарафыннан икенче мәртәбә җиңелде.

Россия клублары өчен быелгы сезонның үзенчәлеге – ВТБ Бердәм лигасының күпчелек матчларында ПБЛ даими чемпионаты зачетына да язылып бара. «Спартак» һәм УНИКС арасындагы уен да шундыйлардан булды. Казан командасы бу юлы, Костас Каймакоглу травма аркасында уйный алмаганлыктан, көчсезләнгән иде. Ул Санкт-Петербургка хәтта оча да алмаган. Шулай ук матчта катнашырга тиеш булган Владимир Веремеенко да паркетта күренмәгән. Уенның уңышсызлыгына, бәлки, УНИКСның 8 көн аралыгында инде өченче уенын читтә уздыруы да сәбәпче булгандыр.

УНИКСның киләсе уены 16 гыйнварда булачак, алар Европа Кубогының икенче төркем турниры кысаларында «Баскет-холл»да алманнарның «Ульм» командасы белән очрашырга әзерләнә. Бу сезонда Евролига квалификация турнирының беренче очрашуында УНИКС әлеге команданы бер җиңгән иде инде.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Без бергә булганда гына көчле!

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ: «ТАТМЕДИА» ААҖ
www.shahrikazan.com
Реклама хезмәте телефоны: (843) 562-50-12

Шәһри КАЗАН
«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы директоры – баш мөхәррир Мансур Газизҗан улы МОРТАЗИН

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: 420066, Казан, Чистай ур., 5 нче йорт
Http://shahrikazan.com
E-Mail: shahri-kazan@tatmedia.com
ТЕЛЕФОННАР: 562-50-12 – кабул итү бүлмәсе, 562-50-07 (факс), 562-63-90 – бухгалтерия, 562-50-03 – хатлар бүлеге.
НӘШРИЯТ: «ТАТМЕДИА» ААҖ, 420097, Казан, Академия ур., 2

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды.

БАСМАХАНӘ: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы
График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 17 сәгатьтә.

Тираж сертификацияләнгән.
Тираж – 3517 данә

Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин.
Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк.
Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.
© Газетада басылган язмаларны файдаланганда, шулай ук өзекләр китергәндә «ШК»дан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга
Заказ 29464
ИНДЕКСЛАР:
54126 (3 тапкыр чыга),
16076 (пәнҗешәмбе саны)
54207 (оешмалар өчен)
Сатудагы бәясе ирекле
12+